Р. Б. ЗАРИПОВА

ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ

Р. Б. ЗАРИПОВА

ГАИЛӘ ҖЫЛЫСЫ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1982

ББК74.115
З-26

Зарипова Р. Б.

З-26 Гаилә җылысы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982.

56 бит.

Һәр ата-ана үз баласын ярата. Ләкин аны ярату гына җитәмө? Киләчәктә ул нинди кеше булып үсәр? Холкы, фигыле, кешеләргә мөнәсәбәте, кылган эшләре белән горурлана алырмы?.. Менә шул хакта һәр ата-ана да вакытында уйланамы?

Әлеге брошюрага кергән мәкаләләрдә сүз гаиләдә бала тәрбияләү, ата-ана белән балалар арасындагы мөнәсәбәт, кеше язмышын формалаштыруда гаиләнең роле турында бара.

З $\frac{60300-150}{М132(03)-82}$ БЗ—48—86—81 ББК74.115

© Татарстан китап нәшрияты, 1982.

АВТОРДАН

Бу җыентыкның туувына укучы хатлары сәбәп булды. Газетаның хатлар бүлегендә эш көне гадәттә укучы хатлары белән танышудан башланып китә. Һәр хат үзе бер вакыйга, үзе бер язмыш. Озак еллар «Татарстан яшьләре» газетасының хатлар бүлегендә эшләү чорында мең андый вакыйгалар һәм язмышлар белән күп очрашырга туры килде. Күп кенә хатларда сүз гаилә, гаиләдә бала тәрбияләү, бүгенге яшүсмер, аның белән дустанә элемтәләр урнаштыруның катлаулылыгы һ. б. ш. мәсьәләләр турында була. Кемдер кулына каләм алып редакциягә хат язарга утырган икән, димәк, аның күңелендә уйланырлык, борчылырлык фикер бар. Шунысы шатландыра, бу хатлар совет кешеләренең үсеп килүче буынны тәрбияләүгә битараф булмавы, чын кеше тәрбияләү мәсьәләсе белән кызыксынып яшәве турында сөйли.

Яшь буынны тәрбияләү — илебез үсешенең һәр чорында дәүләткүләм әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып килде.

Партиянең XXVI съезды карарларында үсеп килүче буынны югары әхлаклылык рухында тәрбияләүнең әһәмиятенә аеруча басым ясалды. Әхлак тәрбиясенең төп нигезләре исә гаиләдә салына. Ата-ана үз хезмәтен яратамы, алар башка кешеләр турында нинди фикердә — болар берсе дә бала игътибарыннан читтә калмый. Шулар йогынтысында әкренләп баланың үз карашы формалаша. Бу җыентыкка кергән язмаларда, тормыш мисалларына таянып, мин укучының игътибарын менә шул мәсьәләләргә юнәлтергә тырыштым. Язмалар өчен, әйткәнемчә, укучы хатлары азык бирде. Хатлар, алардагы вакыйгалар мине уйландырды, автор белән бергә фикерләрне дәвам иттерергә, тирәнәйтергә яки бәхәсләшергә мәҗбүр итте. Укучы хатлары командировка өчен яңа адреслар бирде, үрнәк гаиләләр белән дә, гыйбрәтле хәлләр белән дә очраштырды.

...*Мин үзем әтиемне хәтерләмим. Ул фронтка киткәндә мин әле сабый гына булганмын. Әти исә сугыштан кайта алмаган,*— дип яза Лениногорск районы Түбән Чыршылы мәктәбе укытучысы Мәмдүдә Гыйлаҗева.— *Ләкин гомер уртасына җитсәм дә, әти минем һәм нке апам өчен изге бер көч булып калды. Без барыбыз да әти исемне, аның рухы алдында баш ибез. Моның өчен без иң башлап әнигә бурычлы. Безне ата хакын хакларга ул өйрәтте. Ана — зур көч ул. Баласын кеше иткән дә, кешелексез иткән дә ана...*

Автор шулай ди. Һәм үзенең фикерен раслап тормыштан күп кенә мисаллар китерә. Аның фикерләре белән килешми мөмкин түгел. Әйе, гаиләдә ана кешенең роле искиткеч зур. Гаилә учагының җылысы да, нскып-сүнеп китүе дә күпчелек очракта әниләргә бәйле.

Дөрес, безнең заманда «...ана вазифаларын производствода һәм җәмәгать тормышында актив катнашу белән бергә бәйләп алып баруның никадәр авыр булуы һәркемгә ачык»[1]. Шулай да күпләр үзләренең җәмгыять алдындагы шушы мактаулы бурычын намус белән үтиләр. Әлеге җыентыкка кергән язмаларда мин менә шул фикерне калку итеп күрсәтергә тырыштым.

---

[1] КПССның XXVI съезды материаллары. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1981 ел, 57 бит

ГАИЛӘ УЧАГЫНЫҢ ҖЫЛЫСЫ

Кайсы гына ата-ана үз баласының башкалардан яхшырак булуын теләми? Һәркем тели. Тик баланы һәркем үзенчә ярата, үзенчә тәрбияли.

Профессиясе буенча педагог булмаса да оста һәм зирәк тәрбияче була белгән ата-аналар сокландыра мине. Бу язма — әнә шундыйларның берсе турында.

Киров исемендәге совхозда миңа Зөлфирә Каһироваларда булырга киңәш иттеләр.

— Балалары бик уңган, пөхтә. Бөтен эшне беләләр. Сыерын да савалар, хуҗалыкны да алып баралар, укуда да сынатмыйлар...

Совхоз җитәкчеләре миңа шулай диделәр. Менә без Каһироваларда, алты почмаклы өйнең түрендәге зур өстәл янында хуҗалар белән сөйләшеп утырабыз. Гадәти әңгәмә — бүгенге авыл тормышы, бүгенге көн крестьянының тормыш-көнкүреше, гаиләсе турында.

Шамил белән Зөлфирә гаиләсендә алты бала үсә. Иң элек аларның мөстәкыйльлеге, һәр эштә — өйдә булмасын, фермада булмасын — өлкәннәрне алмаштырырга әзер торулары турында әйтергә кирәк. Сүз арасында мин балаларны күзәтәм. Йорт-хуҗалык эшләре бер җайга ага бирә. Балалар бит кеше бар дип кенә бүтәнчә була белмиләр. Әнә унбиш яшьлек Рөстәм дөньясын онытып кухняда кайнаша: бәрәңге әрчи, суган турый — ашарга әзерли. VII класста укучы Камил 7 яшьлек энесе Нияз

белән ашыга-ашыга каядыр чыгып киттеләр. Төшке ашка кайткан әниләрен алмаштырыр өчен фермага барулары икән. 10 яшьлек Дилә 5 һәм 3 яшьлек сеңелләре Дания белән Фәнияне уйната.

Балаларга яхшы сыйфатлар үзеннән-үзе генә килми. Әйбәт гадәтләр яшьтән үк ныгысын өчен ата-анага күпме көч, тырышлык куярга кирәк.

Тәрбия турында сүз чыкканда кайбер ата-аналар еш кына болай диләр: «Көне буе эштә булабыз. Бала тәрбияләп утырырга вакыт бармыни?» Бу яктан Шамил белән Зөлфирәнең вакыты ничегрәк икән? Мин сүз җаенда шул хакта сораштырам. Шамил һөнәре буенча механизатор. Хезмәтендә башкаларга үрнәк булганы өчен хәзер аны кырчылык бригадиры итеп билгеләгәннәр. Вакыт белән исәпләшмичә, көнне төнгә ялгап эшли торган кеше. Зөлфирә егерме ел инде фермада дуңгыз карый. Әлегә совхозда эш сменалы итеп оештырылмаган; шулай ук тулысынча механикалаштырылган дип тә булмый. Иртәдән кичкә кадәр шунда булырга кирәк. Өйдә иң иртә торучы да, иң соң ятучы да Зөлфирә. Өстәвенә, җәмәгать эшләре дә байтак икән. Зөлфирә алдынгы эшче дә. Ул — Ленин ордены кавалеры, коммунистик хезмәт ударнигы. «Республиканың иң яхшы дуңгыз караучысы» дигән исемне алган кеше; ТАССР Верховный Советы депутаты, совхозның хатын-кызлар советы члены. Күргәнебезчә, Зөлфирә совхоз производствосында да, җәмәгать эшендә дә үз урынын тапкан. Безнең җәмгыятьтә хатын-кызның тоткан урынын, югары социаль дәрәҗәсен хезмәте күрсәтә. Аңа кайчак сессияләргә барганда берничәшәр көнгә өйдән аерылып торырга да туры килә. Ләкин ул югында да өйдәге тормыш бер көйләнгән эздән баруын дәвам итә. Чөнки ул балалар янында булган һәр минутын файдалы итеп үткәрергә гадәтләнгән.

— Өйдә мин югында балалар бөтенесен эшләп куялар. Кайтуыма мичкә ягылган, су китерелгән, ашарга пешкән, сыер савылган була,— ди Зөлфирә.— Рөстәм

булганда бигрәк тә күңелем тыныч. Ул энеләре һәм сеңелләре турында олыларча кайгырта; кушасын куша, гомумән, тыңлата белә. Алар шулай кул арасына кермәсә эшли алыр идемме?

Ә Рөстәм болай ди:

— Безнең әнинең тик утырганын күргәнебез юк. Ул ял иткәндә дә берәр төрле кул эше алып утыра.

Сүз уңаенда тагын шуны әйтергә кирәк, бу гаиләдә бергәләп китап һәм газета-журналлар уку гадәткә кергән. Эшләрне төгәлләп, барысы бергә җыелгач, әтиләре, Шамил агай, Рөстәм яки Камил китап укый, калганнары аны тыңлыйлар. Аннары фикер алышалар, әсәргә һәм андагы геройларга бәя бирәләр. Бу йортка дистәләгән газета-журнал килә. Эш күп булса да, биредә бик матур ял итә беләләр; әтиләре белән бергә малайлар кышын — чаңгыда, җәен мотоциклда йөрергә яраталар.

Ата-ананың тормышка актив мөнәсәбәте балаларның характерында да чагыла. Рөстәм, Камил, Дилә мәктәптә яхшы билгеләренә генә укыйлар, комсомол, пионер эшләрендә үзләре башлап йөриләр. 9 нчы класста укучы Рөстәм — әти-әнисенең иң беренче таянычы. Аның белән төрле темага сөйләшергә мөмкин. Бөтен нәрсә белән кызыксынып, барысын белеп торуы һәр сүзеннән сизелә. Урта мәктәпне тәмамлагач авыл хуҗалыгы институтына барырга ниятләгән.

— Кайчак миннән балаларны ничек тыңлата аласың дип сорыйлар,— ди Зөлфирә,— тиргисендер әле диләр. Бер дә алай түгел. Ачулансам, киресенчә, тыңламаслар кебек. Балаларның да җаен белергә кирәк бит. Әйтик, балаң бик бирелеп дәрес хәзерли яисә телевизор карый икән, син аңа эш кушма инде. Хәленә кер. Үрнәк белән тәрбияләргә кирәк. Минем балаларга ике тапкыр әйткәнем юк. Бер әйтәм, тыңлыйлар. Шулай кирәклеген беләләр. Кечкенәләре олыларыннан күреп өйрәнә.

Гаҗәп акыллы сүзләр. Әйе, баласы булган һәркем тәрбияче булырга бурычлы. Тормыш шуны таләп итә.

Бу гаиләдә балаларның киләчәге өчен тыныч булырга мөмкин. Кая гына китсәләр дә, кем генә булсалар да, алар иң әлек кеше булырлар.

Совхоздан мин шундый уйлар белән киттем.

ИШЛЕ ГАИЛӘ

Безнең урамда Хафизуллиннарны белмәгән кеше бар микән. Танылган яисә берәр батырлык эшләгән кешеләр дә түгел үзләре, юк. Наил Хафизуллин Татарстан мех производство берләшмәсендә слесарь булып эшли, хатыны Сания — заводта. Алар сигез кыз үстерәләр. Менә шушы зур гаилә, аның татулыгы, кызларның тыйнак, эшкә уңган, җитез һәм сәламәт булып үсүләре кешеләрне сокландыра. Шәһәрдә бер яки ике балалы гаиләләргә күнеккәнбез, сигез балалы гаилә бик сәер тоела.

Кайбер ата-аналарга Хафизуллиннар гаиләсендә күп нәрсәгә өйрәнергә мөмкин булыр иде. Сигез бала үстерү җиңел түгел, әлбәттә! Ишле гаиләнең мәшәкатьләре дә, куанычлары да җитәрлек була. Аны Наил белән Сания үзләре генә белә торганнардыр. Ләкин аларның ул мәшәкатьләрне шатлыкка әйләндерә, куанычларны җиңеләйтә белүләренә гаҗәпләнми мөмкин түгел. Монда берәүгә дә «аша, киен, тегендә бар» диясе юк. Олысы да, кечесе дә үзенең ни эшләргә тиешлеген үзе белә. Биш яшьлек Рәмзия дә чәчен үзе тарый, юына, киенә. Унбер айлык сеңелесен дә карый. Аны киендерә, ашата. Беренчедә укый торган Гөлфия нәни Фәриданең киемнәрен менә дигән итеп юып үтүкли. Үз-үзеңне карау, кечкенәләргә булышу гаилә тәртибенә әйләнгән.

Бүген шимбә. Әниләре әле генә эштән кайтып кергән. Өйдә барысы да «ялт» итеп тора. Барысына да кай арада өлгергәннәрдер! Икесе дәрес хәзерләп утыра. Унынчыда укый торган зур кызлары Фирдәвес мәсьәлә чишә,

сигезенчедә укучы Наилә әдәбияттан сочинение яза. Гөлфия белән Рәмзия Фәридәгә нидер сөйлиләр.

Ишле гаилә турында сөйләгәндә материаль якны беренче планга куялар: азык-төлеген, кием-салымын ничек җиткерергә кирәк? Биредә берәү дә үзенә аерым таләпләр куймый «Миңа тегене алыйк, моны алыйк»,— дип әйтми. Башлап кемгә нәрсә алырга. Шул мәсьәләне хәл иткәндә, барысы да катнашалар, һәм моның файдасы зур. Мәсәлән, иң элек Фирдәвескә күлмәк, Наиләгә язгыкөзге пальто алырга кирәклеген алар алдан белеп торалар.

Кызларның киемнәре дә башкаларныкыннан ким түгел. Өйдә дә кирәк булганның барысы бар: холодильник, кер юу машинасы, сервант, телевизор...

Бу гаиләдә тәрбия методы нәрсәдән гыйбарәт соң? Әлеге сорауга җавапны мин хуҗа хатынның сүзләреннән таптым.

— Күз алдына китерегез: берсеннән-берсе кечкенә биш-алты баланы көненә берничә тапкыр юындыра, киендерә, һәркайсының артыннан җыя башласаң?.. Бу мөмкин дә түгел. Кечкенәдән үк мин аларны мөстәкыйльлеккә өйрәтергә тырышам. Аннары тәртип урнаштыруда гаиләдә балалар никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшы. Берәү тәртипкә өйрәндеме, калганнары шуннан үрнәк ала. Иң мөһиме — кечкенәдән үк үз-үзен карарга, кечеләргә булышырга гадәтләнә.

Әйе, кече яшьтән үзләштерелгән гадәтләр гомер буена баралар шул. Сания бөек педагог Макаренко яки башка танылган педагогларның хезмәтләрен өйрәнгәндер дип әйтә алмыйм. Әмма бөек педагогларның хезмәтләренә шушындый ата-аналарның тормыш тәҗрибәсе нигез булганлыгына шигем юк.

...Шаулашып Гүзәл белән Гөлнар кайтып керде. Озайтылган көн группасында алар. Кайтышлый кибеткә кереп, кичке ашка йомшак икмәк, сөт алып кайтканнар. Гөлнар кайтып керүгә мәктәптәге хәлләре турында сөй-

ли башлады. Аны игътибар белән тыңладылар. Математикадан тагын «5»ле алган. Гөлнар Казан мәктәпләренең дүртенче класс укучылары арасында ГТОның беренче баскычы нормаларын уңышлы тапшырган. Хәтта рәсемен республика газетасына урнаштырганнар.

Кыз энисен, аннары әбисен кочып алды, Фәридәнең дә чәченнән сыйпады һәм апалары янына килеп утырды.

— Әбисенең иң яраткан оныгы шушы инде,— диде энисе. Һәм каенанасы турында җылы итеп:

— Һәр нәрсәдә булышчыбыз ул безнең,— диде.

— Сиксән яшькә җиттем инде,— дип сүзгә кушылды әбиләре,— гомер сизелми дә уза икән.

Шундый оныкларың белән шау-гөр килеп яшәгәндә ул турыда уйланырга да вакыт җитмидер. Зиһникамал әбине гаиләдә бик хөрмәт итәләр. Өс-башы чиста, пөхтә. Иң элек табынга аны дәшәләр, һәрнәрсәдә аның белән киңәшләшәләр.

Саниягә әле кырык яшь тә юк. Ире, каенанасы белән 20 елдан артык гомер итә сигез ана баласы! Ничек өйләнешүләре, ничек яшәүләре хакында ул сүзне озынга сузмады.

— Хәзерге яшьләр кебек, бизәлгән машиналарга утырып загска барырга да, бик мул итеп туйлар ясарга да туры килмәде безгә. Ләкин бер-беребездә ялгышмадык. Кыен вакытлар да булгандыр, әмма һәрвакыт үзара ярдәмләшеп яшәргә, бер-беребезнең хәтерен сакларга тырыша идек...

Гадәти генә нәрсәләр турында сөйләшеп утырабыз кебек. Чынында исә кешенең характерын, аның дөньяга карашын формалаштыру, гомумән кеше тәрбияләү турында сүз бара бит. Һәм бу сөйләшүдән әллә никадәр тәҗрибә, сабак алырга мөмкин.

Тышта инде караңгыланып килә. Өйдә ут кабызалар. Баскычта — янә аяк тавышлары. Сменасын тәмамлап әтиләре кайткан икән. Ягымлы елмаеп өйгә керә. Сиздермәсәләр дә, аны күптән көтәләр иде инде. Кызлар

дәресләрен карап бетерделәр. Тиз генә табын әзерләнде. Көндәлек эшне бетереп, барысы да бергә җыелды, һәркайсының күңеле күтәренке иде.

КУАНЫЧЛЫ МӘШӘКАТЬЛӘР

Күптән түгел мин Казанның Ульяновлар урамында яшәүче Кашаповлар гаиләсе белән таныштым. Гаилә башлыгы Искәндәр Кашапов Казандагы 3 нче йөк автотранспорты производство берләшмәсендә алдынгы шофер, аның хатыны Тәскирә апа урта белемле химик-лаборант. Алар сигез бала — биш малай, өч кыз үстерәләр. Бу йортта ата-ананың балаларына киңәш бирүен дә, боерыгын да ишетмәссең. Шулай да олысыннан алып кечесенә кадәр һәркем бөтен эшне күңел биреп эшли, үзара хөрмәт тә, кайгыртучанлык та — барысы да бар бу йортта. Мин Тәскирә һәм Искәндәр Кашаповларның бала тәрбияләүдәге «серләре» белән кызыксынып, аларга берничә сорау бирдем.

Сезнең гаиләдә бу ирләр эше, бусы хатын-кыз эше дигән бүленеш бармы?

— Әгәр дә эшне алай бүлешсәк, миңа борылырга да вакыт җитмәс иде. Балаларыбызның күбесе, бигрәк тә эшкә ярый торганнары, малайлар бит. Иң олы дигән кызыбыз — Эльмирага да 8 генә. Әтиләре идән юу, ашарга әзерләү, савыт-саба юу кебек эшләрне бик рәхәтләнеп эшли, малайлар да әтиләреннән күреп өйрәнәләр. Алар миңа һәм сеңелләренә авыр эш калдырмаска тырышалар.

Балаларыгыз нинди эшләрне эшли беләләр?

— Хуҗалык эшләренең һәммәсен дә. Билгеле, зурраклары: Илдус, Илсур һәм Илһам, аларга 17, 14, 12 яшь. Утын кисәләр, яралар, су савытларын карап кына торалар — суы кимемәгәнме? Мичкә ягу, өй җыештыру,

кечкенәләрне карау, кибеткә бару, ашарга әзерләү дисеңме — гомумән хуҗалыкта, бигрәк тә безнең кебек үз йортлары белән торган кешедә эш җитәрлек. Өйдә үтүк, сәгать, радио кебек нәрсәләр эшләмәсә, мастер чакырган юк. Малайлар үзләре төзәтә. Сүтәләр, тикшерәләр, карыйлар. Барып чыкмаса, әтиләре булыша. Безнең малайлар өйдә генә түгел, чит кешеләргә дә ярдәмчел. Күршебездә Степанида әби һәм Рауза түти яши. Балалар алар турында кайгыртуны төп эшләренең берсе итеп саныйлар. Су китерәләр, кибеткә барып азык-төлеген алып кайтып бирәләр.

Балаларыгызда хезмәткә мәхәббәт ничек тәрбияләдегез?

— Аның белән махсус шөгыльләнмисең, билгеле. Тормыш үзе өйрәтте. Бала карашырга кешебез булмады. Ә гаилә арта барды. Башта Илдус, Илсур, аннары Илһам туды. Кечкенә чакта, балалар бик теләп эшлиләр. Булдыра алса-алмасалар «мин үзем» дип торалар. Мәсәлән, 5 яшендә чагында Илдусны 2 яшьлек һәм яңа туган энеләре белән калдырып, барасы җиремә бара ала идем. Аннары әзрәк үсә төшкәч Илсуры абыйсы вазифаларын бик теләп үзенә алды. Укырга кергәч Илдус мәктәп формасын һәрвакыт үзе үтүкли торган булды, ә энеләре «Кайчан без дә мәктәпкә йөрербез икән!» — дигәндәй абыйларына кызыгып карап торалар иде. Шуны да әйтәсе килә, Илдусның пөхтәлеге калганнары өчен гел үрнәк булды. Ул мәктәпне тәмамлап Түбән Камага нефтьхимия техникумына киткәндә аның мәктәп формасы өр-яңа килеш саклаиган иде. «Минем костюмны кем пөхтә йөри, шул кисен», — дип әйтеп калдырды ул. Илсур белән Илһамга пөхтәлектә ярышырга шул сүз җитте. Форма юклыктан түгел, абыйларыныкы бит.

Миннән еш кына кайбер танышларым:

— Ничек сезнең балалар бөтенесен эшлиләр дә, нигә минекеләр эшләми? — дип сорыйлар. Хәзер, сигез баладан соң, мин моңа җавап таптым кебек. Кечкенәдән эш-

ләтүдән курыкмаска кирәк икән. Күп вакыт аналар балаларын теләп эшләгән җиреннән туктаталар: «Куй, ватарсың, түгәрсең, буялырсың». Берәр тапкыр ватылды, түгелде яки буялды ди? Бала чакта кайсыбыз ватмаган да кайсыбыз егылып борын канатмаган? Элегрәк 2—3 яшьлек баласы булган аналардан: «Балагыз өйдә булышамы?» — дип сорасалар, мин, мөгаен, гаҗәпләнгән булыр идем. Ә югыйсә 2—3 яшьтә бала әнисенә менә дигән ярдәмче була ала икән. Безнең Ләйсән (аңа 2 яшь ярым) чәй әзерләгәндә өстәлгә чынаякларны алып килә, илтеп куя, мин кер юганда яки ашарга әзерләгәндә кечкенә сеңелесе Илсөяне уйната, иң нәни энесе Илнурның арбасын тирбәтә, тагын шундый вак-төяк эшләрне эшли. Дөрес, күзәтеп торырга, кайчак ярдәм итәргә, күрсәтеп бирергә кирәк. Эшләү бер дә зыянга түгел. Ялгыша-ялгыша эшләсә дә, бала эшләсен, тик торырга гадәтләнмәсен.

Балаларыгыз белән ике арада аңлашылмаучылык килеп чыкканы, аларга җәза бирергә туры килгәне бармы?

— Булгалый. Ләкин балаларны ачуланганыбыз юк. Ярамаганны эшләсәләр, әтиләренең бер күз карашы яисә үземнең бер сүзем җитә.

Беркөнне, без өйдә юк чагында, Илгиз кибеттән өч мороженый алып кайткан. Аны өстәлгә куйган да Илһам белән Эльмираны көтә башлаган, икесе аларга янәсе. Илһам кайтып кергән дә нинди акчага алдың дип сорашырга тотынган:

— Степанида әби бирде, — дигән Илгиз бер дә исе китмәгән кыяфәттә.

— Нигә дип акча бирде әле ул сиңа?

— Ипи алып кайтып биргән өчен. Өч тапкыр алып кайттым, һәркайсында 15 әр тиен бирде. Ә мин аны җыеп бардым да, мороженый алдым...

Шуннан тегеләр икәүләп кыздырганнар Илгизне. Безнең катнашуыбызның кирәге дә булмады. Мороже-

ныйны ашаганнар ашавын. Әмма Илгиз әбидән бүтән акча алмаган. Аңлаган күрәсең.

Аннары Илсур белән Илһам узган җәйне үзләре кызык булдылар. Утын кайтарткан идек.

— Бүген утын кисәрбез, урамда озак йөрмәссез,— дип әйтеп куйды әтиләре.

Малайлар ашап-эчкәч урамга чыгып киттеләр дә кичкә таба гына кайтып керделәр. Бер сүз дәшү юк. Күреп торам, уңайсызланулары йөзләренә чыккан. Әтиләре күрмәмешкә салышты. Тегеләре шуннан файдаланып шыпырт кына чыгып шылдылар. Утынны кисеп бетермичә өйгә кермәделәр. Гаепләре өчен үзләренә үзләре җәза алдылар. Иртән әтиләре:

— Дөньягызны онытып йөрсәгез, шулай була ул...— диде.

Малайларга артык сүзнең кирәге дә юк иде.

Шундый хәлләр булгалый инде. Тик алар тавыш күтәрүләрсез, күз яшьләрсез генә хәл итәлә.

Читтә укучы улыгыз өчен тынычмы? Әгәр тормыш аны төрле сынаулар алдына куйса, ялгыш юлга тайпылыр дип курыкмыйсызмы?

— Билгеле, ата-ана баласы өчен беркайчан да тыныч була алмый торгандыр, хәтта балалары үз янында булганда да. Ә шулай да без Илдус дөрес юлдан тайпылыр дип уйламыйбыз. Чөнки аның кечкенәдән үк һәр нәрсәгә карата үзенең ныклы фикере бар. Аңа 12, ә энесе Илһамга 8 яшь чагындагы бер сөйләшүләре истә калган.

Илһамы урамнан елап кергән дә, малайлар белән булган хәлне абыйсына сөйли.

— Мин берни эшләмәдем,— ди Илһам,— тик торганда Вовка пычрак чәчрәтте.

— Ничек инде тик торганда? — дип төпченә башлады абыйсы.

— Малайлар Вовканы үртәделәр дә, үзләре качты-

лар. Ә ул таяк белән тегеләргә чәчрәтмәкче иде, миңа эләкте.

— Ә син тик карап тордыңмы? Кешене үртәргә ярамый дип нигә Вовканы якламадың?..

Ул Илһамны якларга ашыкмады. Аның үзен гаепләде.

Илдус һәр нәрсәне тикшерергә, аңа дөрес бәя бирергә тырыша иде. Аннары энеләре, сеңелләре алдында абруе зур аның. Ә ул моның кадерен бик белә. Бу исә аңа һәр адымын үлчәп атлауны таләп итә. «Алар минем турында ни уйларлар?» Аннары ул, акчаның ничек табылганын да, аны ничек тотарга кирәклеген дә белә. Бер җәйне эшләп 244 сум акча алды. Хезмәт хакына бөтенебезгә бүләкләр алып кайтты.

Балаларыгызның сездән яшерен серләре бармы? Булса, моңа ничек карыйсыз?

— Серләре була, әлбәттә. Кайчак миңа гына яисә этиләренә генә сөйләгән сүзләре була. Һәркайсыбыз сөйләгән серләрен сакларга тырышабыз. Әйтергә теләмәгәнне артык төпченмибез. Шулай да ата-ана булгач, баланың нәрсә белән яшәгәнен белеп торасың. Күңел күзе дигән нәрсә бар бит әле.

ҖИРГӘ МӘХӘББӘТ

Нәкый Зәкиевларның зәңгәр тәрәзәле, алты почмаклы йорты авылның нәкъ уртасында. Авыл кешеләре аны бәхетле нигез диләр. Анда гомер-гомергә тормыш гөрләп барды. Шушы нигездә алты бала — дүрт ул, ике кыз үсеп канат чыгарды. Өч буын кешесе бергә яшәгән бу гаиләдә беркайчан да тавыш-гауга ишетелмәде. Ә гомер, елларны саный-саный, акты да акты. Балалар кече яшьтән үк кул арасына керделәр. Һөнәр сайлар чаклары җиткәч тә Нәкый абзыйның да, Нәһирә апаның да аларга үз карашларын көчләп такканнары булмады. Кулыннан эш килгән кеше кайда да хур булмый. Нәкый абзый

шулай дия иде. Аннары ул балаларының үзеннән белемлерәк булуларын теләде. Һәм аның теләге тормышка ашты. Балалары өчен Нәкый абзыйга кызарырга туры килмәде. Олы улы Фәнис кечкенәдән үк техника белән «җенләнде». Җәйге каникулда да әзрәк буш вакыты булса, тракторчы, комбайнчылар тирәсендә мәш килде, ярдәмче булып йөрде. Яшьтән үк үзен механизатор һөнәренә әзерләде. Менә Фәнис инде унөч ел «Беларусь» тракторында эшли. Аның тракторы сәгать механизмыннан бер дә ким түгел дип сөйлиләр. Икенче уллары Хаккый, колхоз стипендиясенә Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлап, туган колхозына кайтты, зоотехник-бригадир булып эшли. Өченче малай Фирдәвес тә авыл хуҗалыгына теше-тырнагы белән ябышкан. Ул берничә ел инде колхозда механикалаштырылган бәрәңге игү звеносын җитәкли. Ел саен аның бригадасы бәрәңгедән мул уңыш ала. Фирдәвес колхозда гына түгел, районда беренче урында бара. Хатыны Тәнзилә колхозда кирәкле белгеч — алдынгы төзүче. Кече уллары Наил — шофер, армиядән кайтканнан бирле машинада колхоз ашлыгын ташый. Кызлары Фәйрүзә һәм аның ире Илдус — югары белемле педагоглар. Икесе дә авыл мәктәбендә укыталар. Илдус берничә ел инде пропагандист, колхоз яшьләренә политик белем бирә. Төпчек кыз Наилә дә апасы эзеннән китте, укытучы дипломы алып, туган мәктәбендә укыта. Хәзер әнә ул да башлы-күзле булды. Кияве Фирдәвес Әхмәтов та бик уңган егет. Институт тәмамлап, мәктәптә физкультура укыта. Мәктәп балаларын гына түгел, авыл яшьләрен дә спортны яраттырырга өлгерде.

Бервакыт Нәкый абзыйны кордашы, Татарстанның атказанган укытучысы Тәкый Зәкиев мәктәпкә чакыра килде.

— Ата-аналар алдында бер чыгыш ясап аласы иде,— дип сүз башлады ул.— Балаларыңны ничегрәк тәрбияләвең турында. Башкалар да белсен.

Бу тәкъдимне ишеткәч, Нәкый ага аптырабрак калды.

Нәрсә дип сөйләргә? Аның бит беркайчан да үз балаларын ничегрәк тәрбияләве турында уйланганы булмады. Бары тик ата-бабасы яшәгәнчә, тормыш тәҗрибәсенә таянып яшәде. Әтисе колхозга беренчеләрдән кергән тырыш колхозчы иде. Бик теләсә дә Нәкый укый алмады. Җиде яшеннән атасыз калгач тормыш арбасына иртә җигелергә туры килде аңа. Унөч яшендә ул колхозда атлар карый иде инде. Унсигез яшьлек егет булып фронтка китте. Фронттан каты яраланып, күкрәгенә медальләр тагып кайтты. Фронтовик хәрби киемнәрен салырга өлгермәде, идарәдә аңа бригадир булырга тәкъдим иттеләр. Нәрсәгә тотынса шуны булдырырдай бригадир кирәк иде. Ул елларда шунсыз мөмкин дә түгел. Атларга азык юк. Чәчүлек орлык җитми. Барын да табарга, юнәтергә, кешеләрне дә эшләтә белергә кирәк. Шулай да сер бирмәде егет. Нәһирәсе дә күрше бригадада бригадир иде. Өлкән Зәкиевның хезмәт биографиясе менә шулай башланды. Сугыштан соңгы авыр елларны ул бүген дә онытмый. Әҗәкүлдән чәчүлек орлык ташулар, атлар егылгач арбага җигелеп тартулар. Аларны онытып буламы соң?

Шулай ел артыннан ел узды. Тырышлыгын күреп аны фермага мөдир итеп куйдылар. Кайда гына эшләсә дә, ул булган җирдә эш гөрләп барды. Ферма мөдире буларак, Мәскәүдә Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә катнашты. Соңгы елларда район партия конференциясенә делегат булып сайланды, күп тапкырлар бүләкләнде. Нәкый абзый хәзерге вакытта колхозда янгын сакчылыгы буенча өлкән инспектор. Ә урып-җыю чорында ындыр табагында ул алыштыргысыз кеше. Әйе, гомеренең узган кадәресе гел хезмәттә, җиргә мәхәббәт белән үткән. Балалар, гаилә эшләре белән шөгыльләнергә вакыты да булмаган кебек. Шулай да Нәкый абзыйның бала тәрбияләүдә үз «педагогикасы» булган. Улларын иркә, җебегән итеп күрәсе килмәде аның. Аларга кырыс, ләкин гадел булырга тырышты. Ир кеше

икән — ир булсын. Елаклык кызларга да килешми. Шушы хакыйкатьне ул хатынына да, әнисенә дә үзенчә аңлата килде.

Бервакыт ул кояш чыкканчы ук улын уятырга кушты.

— Анасы, тиз генә Фәнисне уят, ат алып кайтсын.

— Әллә соң үзең генә алып кайтасыңмы, атасы,— дип каршы төште хатыны, улын иртәнге йокысыннан уятырга кызганып.

Нәкый абзыйның җавабы бик кыска булды.

— Малайны уятырга кызганасың икән, үзеңә чабарга туры килә инде.

Фәнис тә бу сөйләшүнең ни белән бетәсен тыңлап яткан икән. Эшләр болайга таба киткәнен сизгәч, ул шунда ук сикереп торды...

Әгәр әтисе яки әнисе шул чакта баланы уятырга кызганып үзләре киткән булсалар, кем белә, Фәнис нинди булып үсәр иде икән. Кечкенәдән өйрәнгәне аның гадәтенә, характер үзенчәлегенә әйләнгән. Ярдәм сорап төнлә килсәләр дә ул баш тартмый. Техника белән эш иткәч, аларга авылдашлары төрле йомыш белән киләләр. Кемгәдер печән яки утын кайтартырга, тегермәнгә он илтергә кирәк була. Андый чакта Зәкиевлар беркайчан баш тартмый. «Зәкиевлар булса, булдырырлар, әтиләренә охшаганнар алар». Яңа Әлем халкы гадәттә шулай дияргә ярата.

Бу уңайдан Нәкый абзый улы белән булган бер сөйләшүне һич онытмый. Тегермәннән он алып кайтырга кирәк булды һәм ул Фәнисне чакыртты. Кич белән Фәнис урынына ике егет килде.

— Үзе ник килмәде? — дип сорады өлкән Зәкиев егетләрдән.

— Хәмит абзыйга китте, үзе урынына безне җибәрде.

Икенче көнне улына бу хакта әйткәч, тегесе:

— Мин Хәмит абзыйга утын кайтарырга вәгъдә иткән идем,— ди.

— Әтиең сораганда теге егетләрне анда җибәрәсең калган,— ди әтисе.

— Юк инде, эткәй, вәгъдә — иман,— диде егет елмаеп.— Үзең шулай өйрәттең,— дип тә өстәде.— Хәтерлисеңме, атлар караганда сиңа ярдәм сорап киләләр иде. Өйгә кайтмасаң-кайтмыйсың, әмма кеше гозерен үтәми калмый идең.

Нәкый абзыйга сүз әйтер урын калмады. Әйе, атасы улы икән шул бу егет.

Кайвакыт дәү әниләре дә малайларны яклап арага кергәли. Әниләре өйдә юкта әтисе 12 яшендәге Фирдәвескә сыер савып керергә кушкач:

— Кит инде, егет кеше сыер сауганны кайчан күргәнең бар,— дип каршы төште дәү әнисе.— Күрше хатынын чакырып чыгарга кирәк.

Бу юлы да атаның талканы коры булды:

— Буй җиткән улың өйдә була торып кеше чакырыргамы?

Шул көннән башлап Фирдәвес сыер саварга өйрәнеп китте. Кушканны да көтми, үзе чыгып сыер сава торган булды.

Баштарак, өйләнешкән елларны Нәһирә белән каенанасы арасында да низаглар күренгәли иде. Әле хатыны, әле әнисе ялгыз калган чакта аһ-зарларын Нәкыйга сөйләп калырга тырышалар:

— Киленне әйтәм, эшкә киткәнче су китереп китмәгән шунда.

— Мин көнозын эштә, әнкәйгә керләр юып алса булмыймы...

Мондый чакларда Нәкый абзый «телсез-чукрак» булуны кулайрак күрде. Тегеләр моңа эчләрен бушата торалар, ә ул берсен дә якламый. Тора-бара килен белән каенана үзара дуслашып китәләр, вак-төяк бәхәсләрдә еш кына аларның икесе бер сүздә булуын күреп Нәкый абзаң мыек астыннан елмаеп йөри башлый...

Нәкый абзый нык характерлы кеше. Нинди генә

авырлык килгәндә дә авылдашларыннан берәүнең дә аның зарланганын ишеткәне, йомшап калган чагын күргәне булмады. Ә бүген менә аңа әллә нәрсә булды. Өстәл түрендә туй киемендә кияве белән янәшә утырган кече кызы Наиләгә карап, уйга чумды:

— Бигрәк тә анасы булыр икән! Мәрхүмә үзе генә күрә алмады бит төпчегенең туен.

...Хатыны Нәһирә кинәт кенә авырып түшәккә егылды. Авыруның башка аякка басмаячагын белгән Нәкый абзый хәсрәтен эченә йотты, тышка чыгармады, карт әнисенә дә, балаларына да сиздермәскә тырышты. Йорт, хуҗалык эшләре көйләнгән эздән бара бирде. Әниләренең авыруы озакка сузылды, хәле яхшыруга таба бармады. Шулай да өйдәгеләр барысы да аның терелүен көттеләр. Моңа бигрәк тә йорт тоткасы — ата кешенең үз-үзен тотышы булышлык иткәндер. Чөнки Нәкый абзый хатынының да, балаларының да күңелләрен төрлечә күтәрергә тырышты: «Әниегез терелгәч моны болай итәрбез, тегене тегеләй итәрбез»,— дигән сүзләрне теленнән төшерми иде. Балалар ярдәмгә мохтаҗ әниләре яныннан төнлә дә, көндез дә китеп тормадылар. Ул чакта олы уллары Фәнис кенә өйләнеп башка чыккан иде әле. Авыру әниләре янында барысы да алмашлап төн үткәрделәр. Нәһирәнең өс-башы, урын-җиренә кер дә тигезмәделәр, теләгән ризыгы алдында булды. Менә шундый борчулары һәм мәшәкатьләре, курку катыш өмет-ышанычлары белән өч ел үтте. Әмма әниләре рәтләнә алмады...

Табында утыручылар Нәкый абзыйның авыр уйларга бирелеп китүен сизеп:

— Атасы, котлап берәр сүз әйтәсеңме әллә,— дип сүз куштылар. Нәкый абзый үзен тиз кулга алды. Бераздан ул җылы, мәгънәле итеп тост әйтте, кызы белән киявенә бәхет теләде.

Ә бәхетнең хезмәт җимеше икәнлеген Нәкый абзый гаиләсендә барысы да бик яхшы беләләр. Крестьян хез-

мәте. Кешеләр җир эшкәртәләр, иген игәләр, терлек асрыйлар, үз эшләрен теләп яратып башкаралар, җиргә-туфракка гашыйк алар. Зәкиевлар династиясе дә шулай. Җиргә мәхәббәт алар токымында буыннан-буынга, каннан-канга күчеп килә.

Көн саен ындыр табагына эшкә барганда яки кайтканда Нәкый абзый балаларын, оныкларын очрата. Һәм шатланып уйлап куя: алар токымы ишәя, туган туфракта тамырлары тирәнәя бара.

ХЕЗМӘТ ШАТЛЫГЫ

«Эшкә барсам бөтен борчуларым онытыла», «Хезмәтем шатлык бирә», «Эшләми торсам авыруга сабышам». Шулай диючеләрне ишеткәнегез бардыр. Болар барысы да кеше тормышында хезмәтнең никадәр зарури булуы турында сөйли торган сүзләр. Һәм безнең илебездә һәркем, кайда гына булмасын, үз хезмәтеннән ямь һәм тәм табып эшли. Алар өчен хезмәт чын мәгънәсендә тормыш ихтыяҗына әйләнгән. Бу зур бәхет, әлбәттә. Ләкин кайчак ата-аналар үз теләкләре белән балаларын менә шушы олы бәхеттән мәхрүм итәләр. Менә бер хаттагы сүзләргә игътибар итик.

«Мин балачактан ук шофер булырга кызыга идем. Әллә инде әтием һөнәре булганга, белмим. Ләкин әлегәчә яныннан выжылдап узып киткән машиналарга тыныч кына карый алмыйм. Һичшиксез рульдә кем утырганлыгын күзәтәм. Билгеле, шоферлар күбесенчә ирләр. Шулай да, минем өчен хыял булып калды бу һөнәр. Мин әнием теләге буенча медицина институтына кердем. Ул шофер булу турында авыз да ачтырмады, кызлар эше түгел ул дип кистерде дә куйды. Берничә елдан мин врач дипломы алачакмын. Ләкин миннән нинди врач чыгар икән? Күңелем ятмый минем. Йөрим инде шунда»...

Әйе, кайбер ата-аналар яхшы хезмәт, начар хезмәт, чиста эш, пычрак эш дип сөйләргә яраталар. Нәтиҗәдә бала кечкенәдән үк кайбер профессияләргә һәм ул профессия буенча эшләүчеләргә түбәнсетеп карый башлый. Ә бит кеше бары тик үз күңеленә ошаган эштә генә тулысынча ачыла һәм канәгатьләнү кичерә. Яраткан хезмәтнең кыенлыклары да сизелми.

Кешенең характеры гадәттә иң башлап гаиләдә формалаша дигән идек. Аның гадәтләренә дә, кешеләргә, хезмәткә мөнәсәбәтенә дә нәкъ менә гаиләдә, ата-ана йогынтысы белән нигез салына бит. Күпләр менә шуңа игътибар итмиләр.

Тагын кайбер мисалларга тукталасы килә.

Төшке аш вакыты җитүгә ашыга-ашыга Мәдинә апа кайтып керде. Капкадан килеп керде дә туп-туры бакчага юнәлде. Бәрәңге алып чистартты, аны пешерергә куйды һәм кечке аш хәстәрен күрә башлады.

— Житкән кызың өйдә ич, Мәдинә апа, нишләп ул хәтле кабаланасың? — дип сорадым.

Ана авыз чите белән генә елмайды да:

— Үзем исән чакта бердәнбер кызымны йорт мәшәкатьләре белән интектерәмме соң. Миннән башка яши башлагач та җәфаланырга өлгерер әле,— дип җавап бирде.

Бик сәер тоелды ананың бу сүзләре. Колхоз эшеннән кайтып бераз ял итеп алу урынына, ул бөтенесенә үзе йөгерә: ашарга әзерли, идәнен, керен юа, терлеген карый, ә үсеп җиткән кызына эш кушарга кызгана. Үзенә ничек тә ярый, тик кыз гына «җәфаланмасын».

Әйе, хезмәтне михнәт дип кенә исәпләүче ата-аналарны да очратасың. Алар үзләренең мондый ялгыш карашлары белән балаларын тормышта иң гади эшкә дә сәләтсез, ялкау булып үсәргә булышлык итсәләр, икенчедән үзләре өчен бәхетсез картлык әзерлиләр. Кеше җилкәсендә генә яшәргә күнеккән, хезмәтнең тәмен белмәгән кеше, гадәттә башкалар турында кайгыртырга да

сәләтле була алмый. Әлеге мисалыбызга кире кайтыйк әле. Гел әнисе эшләгәнгә генә ияләшкән кыз әнисенә чынаяклар юарга булышуны да кирәк санамый. Ул сәгать 12 ләр тирәсендә йокыдан тора, әзерне ашый, әнисе юып үтүкләгән күлмәкне кия һәм йөрергә чыгып китә. Мәдинә апа шәһәргә яки район үзәгенә барса, кызына кием-салым эзләп арып бетә. Эшне яратмаса да, киенергә ярата Дания. Әнисе алган күлмәкләрнең әле бер җирен, әле икенче җирен ошатмый. Әнә шулай иркәләп, назлап үстерәләр бердәнбер кызларын. Йорт мәшәкате, хәтта иң гади эш күнекмәләре дә аның өчен ят нәрсә. Әти-әнисе Данияне бәхетле итәселәре килә. Мин Данияне чын-чынлап кызганып куйдым: ничек яшәр икән ул әнисеннән башка? Матур итеп тормыш кора алырмы?

...Рәмзия дә уналты яшьтә. Быел унынчы класста укый. Бервакыт (кыз әле җиденче класста гына укый иде) аларга кергән чагым искә төште. Өстәл өстендә яңа гына пешкән мич ашлары. Кызарып, күпереп пешкән, тәмле исләре бөркелеп торган ризыкларны күргәч, сорамый булдыра алмадым:

— Кайсыгыз шул хәтле оста итеп әзерли белә?

Әнисе, Рәмзия дигәч, мин аптырап калдым. Әле ундүрт яше дә тулмаган кыз шундый осталыкка ничек өйрәнгән?

Без сөйләшкән арада сөте мөлдерәп торган чиләген күтәреп Рәмзия үзе килеп керде.

— Син әллә сыер сава беләсең инде, Рәмзия?

— Сыер да сава белмәсәң,— дип оялчан гына елмайды ул.

— Рәмзия бөтен эшне белергә тиеш, ул бит малайлар арасында бер генә кыз,— дип өстәде әнисе.— Йорт эше күбесенчә аның җилкәсендә. Абыйларын да үзе тәртипкә өйрәтә. Тегеләре аяк киемнәрен урамда ук чистартып керәләр. Мин үзем еш авырыйм. Озак-озак больницаларда ятарга туры килә. Ул чакларда Рәмзия бөтен эшне үзе эшли.

Дәресен хәзерләргә вакыт калмыйдыр дип уйларлар. Юк, Рәмзия барысына да өлгерә: ул мәктәптә яхшы укый. Укучылар куйган концерт-спектакльләр аңардан башка узмый. Җәй көне колхозга булыша. Хәер, кызның кулыннан килмәгән эш юк. Аның җитезлегенә, уңганлыгына сокланмыйча мөмкин түгел. Билгеле, монда атаананың йогынтысы турында әйтми калырга ярамый.

Бер үк шартларда яшәүче ике гаилә, ә икесендә ике төрле тәрбия һәм нәтиҗәдә ике төрле характер формалаша.

Хезмәткә мөнәсәбәт кешенең рухи тормышында гаять әһәмиятле нәрсә. Бу уңайдан күренекле педагог В. А. Сухомлинский болай ди: «Шатлык хисе көч куя, тир түгә һәм арыганлыкны тоя белгән кешегә генә хас. Балачак тоташ бәйрәм генә булырга тиеш түгел. Хезмәт киеренкелеге юк икән, бала өчен хезмәт бәхете дә юк».

Шушы олы бәхеттән балаларны мәхрүм итмәскә кирәк. Алар яшьтән үк хезмәтнең тәмен тоеп, үзләре эшләгән эшләрнең нәтиҗәсен күреп горурланырга өйрәнеп үссеннәр.

КҮҢЕЛ ҖЫЛЫСЫ

— Беләсезме мине нәрсә борчый,— диде миңа күптәнге танышым, укытучы кеше.— Искәргәнегез бармы икән, кайбер яшьләр өлкәннәр янында сүз таба алмыйлар.

Һәм ул түбәндәге вакыйганы сөйләде.

— Сәяхәт вакытында, бер шәһәргә тукталдык. Шуннан файдаланып, элеккеге сабакташымны күреп чыгарга булдым. Эзләп табып кердем, 15 яшьлек улы гына өйдә иде.

— Әниең кайчан кайта? — дип сорадым. Ә ул җавап урынына җилкәсен генә җыерды.

Мин аңа үземнең кем икәнлегемне әйттем. Ә аның әз

генә дә исе китмәде. Керегез, утырыгыз дип тә әйтә белми ичмасам. Аптырагач, үзем кердем. Әнисе кайтканчы көтеп торачагымны белдердем. Уздым, утырдым. Яшүсмер белән сөйләшергә тырышып карыйм... Әниләре кайтканчы икебез ике бүлмәдә сәгатьләр буе сүзсез утырырга туры килде.

Әйе, минем үзем белән дә шуңа охшашлы хәл булганы бар. Бервакыт эш белән хезмәт ветераны янына килгән идем. Ишекне 15—16 яшьләр тирәсендәге оныгы ачты. Исәнләштем. Әлеге яшүсмер авыз эченнән генә нидер мыгырданды.

Миңа фәлән-фәлән кеше кирәк иде, өйдәме? — дим.

— Өйдә,— диде яшүсмер һәм, караңгы алгы бүлмәдә ялгызымны калдырып, үз бүлмәсенә кереп югалды. Бабайның бүлмәсен үземә эзләп табарга туры килде.

Бабайның оныгы турында элегрәк сөйләгән сүзләре хәтергә килде. «Искиткеч аңлы, зиһенле бала, белмәгәне юк. Дөнья әдәбияты белән таныш». Ихтимал, шулайдыр да. Ләкин аның әлеге очрашуда үз-үзен тотышы кешегә игътибарсызлыгы, мәгънәсезлеге күңелдә авыр тәэсир калдырды.

Тормышыбызның һәр көне безне төрле яшьтәге, төрле характерлы кешеләр белән төрле шартларда очраштырырга мөмкин. Шул очрашулардан чыгып без гадәттә теге яки бу кеше турында фикер йөртә башлыйбыз. Киеменә карап каршылыйлар, ди халык. Чыннан да монда кешегә карата иң беренче тәэсир турында сүз бара. Еш кына менә шул мөнәсәбәтләрне дәвам иттерүдә ачкыч булып тора да. Тик бу мәсьәләдә минем шуны искәртәсем килә: тирә-юньдәгеләрдә үзең турында яхшы тәэсир калдыру теләге, сине кеше күрсен дә, уңай бәя бирсен өчен генә түгел, ә бәлки үзеңнең эчке дөньяңның ихтыяҗы булырга тиеш.

Еш кына яшүсмерләрнең өлкәннәр белән аралашканда иң гади нәрсәләрне дә белмәве күзгә ташлана. Бу нидән шулай соң? Әлеге сорауга беркадәр ачыклык

кертү өчен бер гаилә мисалына тукталам. Ул гаиләдә ике малай үсә. Бу малайларның әйтерсең бернәрсәдә дә гамьнәре юк. Өйгә хәтта туганнары, танышлары килсә дә, аларның исе китми. Тик бер генә җавап: әти-әни өйдә юк. Әти-әниләре өйдә булсалар, алар кеше килгәч я үз бүлмәләренә кереп бикләнәләр, я урамга чыгып таялар. Шунысы гаҗәп, бу малайларның чит кешеләр белән түгел, үз әти-әниләре белән дә сөйләшер сүзләре юк. Әти-әнигә эндәшүләре дә я ашыйсы килгәндә, я берәр нәрсә кирәк булганда гына. Әти-әниләренең дә моңа әллә ни исләре китми. Ә балага аралашу, шатлык-борчуларын уртаклашу һава кебек кирәк нәрсә. Юкса аның рухи дөньясының камиллеге турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Шул хакта әлеге ата-анага әйткәч, ата кеше кул гына селтәде:

— Үзләренә кирәк булгач өйрәнерләр, башлары яшь әле.

Әйе, әлегә башлары яшь, аларның берсе 12, икенчесе 9 яшендә. Ләкин гаиләдә шундый мөнәсәбәт хөкем сөргәндә, аларның үсеп җиткәч кенә аралашучан, кеше турында кайгыртучан булырларына ышануы кыен шул.

Балада аралашу ихтыяҗы бик яшьтән үк барлыкка килә. Башта яшьтәшләре, аннары күршеләр, дуслар, туганнар, таныш-белешләре белән. Аралашу ихтыяҗын үстерү дә, үтерү дә күбесенчә ата-анага, аларның тормышта үз-үзләрен тотышына, кешеләргә булган мөнәсәбәтләренә бәйле. Әгәр алар кеше сөймиләр, кунакка йөрешмиләр, гомумән, үз кабыкларына бикләнеп яшиләр икән, мондый гаиләдә үскән балалардан нәрсә таләп итәсең? Мондый шартларда бала күңелендә әкренләп үз-үзен генә яратучанлык, тирә-юньдәгеләргә карата илтифатсызлык сыйфатлары тамыр җәя башлый. Андыйлар кеше шатлыгына шатлана, кайгысына борчыла белүдән ерак торалар. Бу исә шәхес өчен бик куркыныч.

«Литературная газета»ның бер санында мондый вакыйга турында сөйләнгән иде. Кыш уртасында бер шофер

бәхетсезлеккә юлыккан, төнлә купердән төшеп киткән. Ул бозлы судан чыгып, көч-хәл белән якындагы авылга килеп җитә. Берәр кеше бусагасына барып егылсам котылам, дип уйлый ул. Ләкин, кызганычка каршы, шофер егет хыялланган бусагадан аны кертмиләр. Ярдәмгә мохтаҗ егет шунда һәлак була.

Коточкыч фаҗига түгелмени бу? Менә ни өчен кешенең балачактан ук үзенең тар дөньясында гына бикләнеп яшәмәве, тормышка мөмкин кадәр киңрәк әхлакый күзлектән карый белүе бик мөһим. Һәр гаилә, һәр ата-ана бу хакта уйланырга, баласының рухи дөньясын киңәйтү турында мөмкин кадәр иртәрәк кайгыртырга тиеш.

«Залесный» совхозында Зарифҗановлар гаиләсе яши. Ире Юдино тимер юл депосында, хатыны газ буенча слесарь булып эшлиләр. Алар дүрт кыз үстергәннәр. Бу гаиләдә киң күңелле кешеләр яшәве турында бөтен совхоз белә. Алар ачык йөзлеләр, тәмле сүзлеләр.

Әлеге гаиләдә иң беренче тапкыр булуымны хәтерлим. Өйдә VIII класста укучы Гөлсинә һәм аның иптәш кызы гына иде. Гөлсинә мине, ул чакта таныш булмаган бер кешене, ачык йөз белән каршылады. Шунда ук чәй әзерләде. Өстәлгә яңа сауган сөт, яңа өлгергән кыярлар китереп куйды. Гөлсинәнең мондый мөстәкыйльлеге, һәммә нәрсә белән хәбәрдар булуы миңа бик ошады. Мондый очракларда аның яшендәгеләрдән бер үк җавапны ишеткәләргә туры килгәнгә, мин аннан болай дип сорадым:

— Үзләре өйдә юкта кунак сыйлаганга әти-әниең сүз әйтмиме соң?

— Безгә ул кечкенәдән: «Килгән кешегә караңгы чырай күрсәтмәгез, игътибарлы була күрегез»,— дип әйтеп кенә тора иде.— Әти-әни үзләре дә бик кунакчыл. Апаларым ял саен иптәш кызларын алып кайталар, әни үзе шулай куша. «Тулай торакта яшәгән иптәш кызларыгызны да алып кайтыгыз, мунча кереп, кунак булып китәрләр»,— дип әйтеп җибәрә...

Бу гаилә белән якынрак танышкан саен мин алар-

ның яшәү рәвешен тирәнрәк аңлый бардым. «Үз кайгым», «кеше кайгысы» дип аермыйлар алар. Ил кайгысын үзенеке итеп яши торган кешеләр. Һәм алар балаларын да шул нигездә тәрбиялиләр.

Ата-ананың үрнәге бу очракта да зур роль уйный. Әгәр ата-ана тирә-юньдәге кешеләр — күршеләре, хезмәттәшләре белән эчкерсез мөнәсәбәтләрдә яши, ярдәмгә мохтаҗ кешегә булышырга һәрчак әзер тора икән, билгеле, андый гаиләдә балалар яшьтән үк кешелекле, игътибарлы, киң күңелле, ярдәмчел булып үсәләр.

ОНЫТЫРГА ХАКЫБЫЗ ЮК

Ул көнне Таһирны бакчадан алырга әтисе килгән иде. Йөрешеннән, кыяфәтеннән малай аның нинди хәлдә булуын бик тиз аңлап алды. Киенә торган җиреннән туктап, нәфрәтләнеп әтисенә карады.

— Мин синең белән кайтмыйм,— диде малай, еларга җитешеп.— Син тагын исерек.

Әле алты яше дә тулмаган бала исерек әтисенә карата менә шулай ризасызлык белдерә. Әгәр бу хәл кабатланса, баланың атадан күңеле кайтса? Ата кеше үз-үзен кулга алып, шул турыда тирән уйланмаса, мондый фаҗиганың булуы бик мөмкин.

Ата-ана. Бала өчен алардан да якын, алардан да кадерле кем бар? Тормышта бала иң беренче алар белән аралаша, әйләнә-тирә дөнья турында беренче тәэсирләрен алар аша ала, акны карадан, яхшыны яманнан аерырга алар ярдәмендә өйрәнә. Кемнән генә сорасагыз да, аның тормышында иң изге, кабатланмас хатирәләре әти-әнисе белән бәйләнгән булыр. Димәк, ата-ана үзенә күрә бер коллектив та икән ул. Шунда кеше шәхесенә беренче нигез ташлары салына. Аның нинди шәхес булып җитлегүе күбесенчә шул коллективтагы атмосферага һәм аның членнарының үзара мөнәсәбәтенә, үз-үзләрен тотышына бәйле.

Балалары өчен үрнәк булып торучы ата-аналар бик күп бездә. Ләкин бу юлы сүз алар турында түгел.

«Минем киләчәк тормышым нинди булыр,— дип яза Куйбышев районыннан 17 яшьлек бер кыз,— ул турыда уйларга да куркам. Чөнки хәзерге тормышым газап эчендә үтә. Аракының нинди бәлаләр китерүен кайберәүләр белмиләрдер. Ә мин моның ачысын үзем татыдым. Безнең әти көн саен диярлек эчеп кайта, тузына, балалар алдында теләсә нинди сүзләр сөйли. Без, биш бала һәм әниебез, аның кыланышларыннан тәмам туйдык инде. Иптәш кызларым арасында шаяра-көлә алмыйм, егетләр белән дуслашырга да кыймыйм. Кемгә генә, ни генә әйтсәм дә «әтисе шундый аның» диярләр төсле...»

Әйе, балаларга икеләтә авыр. Бердән, көн саен кабатланып торган тупаслык, урынсыз рәнҗетелүләр. Икенчедән, бу хәлне тирә-юньдәге кешеләр белүдән хурлану.

Бала тормышында уку, мәктәп дәресләре — иң мөһиме. Ләкин эчүчелеккә бирелгән аталарны баласының ничек укуы, нинди белемнәр алуы кызыксындырмый.

Гыйбрәтле бер вакыйганы гына сөйлисем килә.

Алар безнең күршеләр иде. Рафис белән Рәмилә һәм аларның әти-әнисе. Әтиләре — шофер, әниләре вертолет заводында кассир булып эшли иде. Бу гаиләнең татулыгына сокланмаган кеше булмагандыр. Кая гына барсалар да алар гел бергә иде. Балачагы күз алдымда үткәнгәме, Рафисы аеруча нык истә калган. Кызлар кебек йомшак күңелле, хисчән малай иде ул. Әнисе өчен өзелеп тора иде. Аккош күле буена алар белән бергә ял итәргә барганыбыз бүгенгедәй хәтердә. Рафис вак балыклар тотса да, берәр матур чәчәк өзсә дә хәзер әнисенә китереп күрсәтә, әнисенең елмаюы аның өчен дөньяда иң зур шатлык.

Ул чакта мин гаилә бәхете шундый булырга тиеш дип уйлый идем. Шунда берәрсе, күрәзәлек итеп, бу гаиләнең бәхетсез киләчәге турында сүз әйтсә, мин һич кенә дә ышанмаган булыр идем.

...Рафис икенче классны тәмамлаганда, аларга Ленин районында өч бүлмәле квартира бирделәр. Шуннан соң алар белән аралашу сирәгәйде. Тора-бара бөтенләй бетте.

Аннан бирле инде ун ел чамасы вакыт үткән. Шулай бервакыт Үзәк культура һәм ял паркында мин таныш йөзне очраттым. Кара-кучкыл йөзле, озын буйлы бу егет чыннан да Рафисмы? Ул булса, нигә соң күрмәмешкә салышты? Бала-чагындагы сизгерлеге, игътибарлылыгы бер дә калмады микәнни Рафисның. Аллеялар буйлап икенче тапкыр әйләнгәндә, мин аны чыннан да таныдым. Ләкин ул, ни сәбәптәндер, мине күргәч, карашын читкә борды. Нәрсә булган аңа?..

Яшьләр белән ачыктан-ачык сөйләшүе җиңел түгел. Әгәр ул егет кеше булса, бигрәк тә. Егетләр бит алар зарланырга яратмыйлар. Ул көнне сөйләшеп булмады, ләкин Рафисны мин тагын очраттым. Бу юлы аның үткәне турында күп нәрсәләр ишеттем.

Зур фаҗига кичергән Рафис. Сөйләвенә караганда, бу хәлләрнең башы мул табын белән үткәрелгән өй туена барып тоташа иде. Ул көнне аларга бик күп кунаклар килгән. Өстәл тулы төрле эчемлекләр. Төнгә кадәр җыр, бию тавышлары тынмаган. Рафис белән Рәмилә, гадәттәгечә, йоклап китәр алдыннан әниләреп көткәннәр. Ләкин ул кунаклардан аерыла алмаган.

...Аннары Рафисның беренче җинаяте. Үзен-үзе белештермичә, классташ малаен кыйнаган. Ни өчен? «Синең әниең исерек» дигән өчен. Рафис өчен иң авыр көннәр менә шуннан башланган. Нәрсә булган аның әнисенә? Нигә алар әтисе белән көн саен кычкырышалар? Аңа әнә шул сораулар тынгы бирмәгән. Әллә нинди ямьсез сүзләр әйтелә. Элек йокларга ятар алдыннан карават янына килеп утыра, һәр икесенең чәченнән сыйпап китә торган әниләре бөтенләй үзгәргән. Күрәсең, ул хәзер балаларын яратмый башлагандыр?.. Әнисен яклап сугышулар дисеңме. Караучысыз малай буларак мили-

циянең балалар бүлмәсендә учетта торулар. Әтисенең әйберләрен алып чыгып китүе. Әнисенең лаякыл исереп кайтуы... Кемнендер киңәшен тотып, тынычланып булмасмы дип аракы эчүләр... Тик бернәрсә дә борчуларын баса алмаган малайның.

Аның нервлары бу кадәр киеренкелеккә чыдамаган. Ул, каты авырып, больницага кергән.

Шуннан соңгы елларын алар балалар йортында үткәргәннәр. Әниләрен ана булу хокукыннан мәхрүм итсәләр дә, Рафис та, Рәмилә дә аның килүен түземсезләнеп көткәннәр. Ялга каршы көннәрдә Рафис һава торышын игътибар белән тыңлый торган булган. Көн генә бозыла күрмәсен. Бәлки килер әле. Менә шулай айлар, еллар үткән. Тик әни кеше күренмәгән. Рафисның төннәр буе утырып язган хатлары да җавапсыз калган...

Сөйләшү вакытында мин шуны аңладым: Рафисның үткәннәрне һич кенә дә исенә төшерәсе килми. Башта мине күрмәмешкә салынып китүе дә шуңа булган икән. Әйе, авыр кичерешләр белән үткән еллар бу егетнең характерында үз эзен калдырган.

Кайчан да булса язмыш аны яңадан әнисе белән очраштырырмы? Алар арасындагы җылы хисләр кабат туармы? Бу сорауга әлегә уңай җавап бирүе бик кыен.

АНА ЯЛГЫШЫ

Мәрьям апаның кайгысы зур. Улы Зиннәт өчен борчылудан авыруга сабышкан. Зиннәте төрмәдә, урлашкан өчен ябылган. Икенче тапкыр утыруы инде. Әле хәзер дә Мәрьям ападан: «Улыңны ни өчен утырттылар?» — дип сорагач, ул: «Бер гаепсезгә, беткәнмени явыз кешеләр»,— дип үзенең «сөттән ак, судан пакь» улын аклап сөйли башлый. Шундый хәлләрдән соң да бу ананың баласының гаебен танымавы бик аяныч. «Мин эчәргә дә, пачар

булырга да кушмыйм аңа, минем улым әйбәт, тик дуслары гына начар, аны шулар өйрәтә»,— ди ана.

Типсә-тимер өзәрлек утыз тулып узган бу егетне җинаять юлына этәргән сәбәпләр нәрсәдә соң? Нигә аның тирә-ягындагы кешеләр барысы да шулкадәр гаделсез булган?

Мәрьям апа Зиннәтне нигәдер башка балаларына караганда артыграк иркәли. Ялганласа да, кечкенәләрне кыерсытса да әнисе аны ачуланмый.

Зиннәт мәктәптә яхшы укый. Фәннәр аңа җиңел бирелә. Ата-аналар җыелышында укытучылар да Зиннәтнең сәләтле булуы турында әйтәләр. Малай тиздән масая башлый. Дәресләрдә башка эшләр белән шөгыльләнә. Аның мәктәптәге шуклыклары турында әти-әнисе белән сөйләшеп, бергәләп аңа йогынты ясау өчен, Зиннәтнең класс җитәкчесе аларның өенә килә. Кызганычка каршы, малае алдында ук Мәрьям апа укытучы белән тиргәшә башлый.

Җәйге каникул вакытында Зиннәт тә иптәшләре белән колхозга булыша. Ул елларда малайлар ат белән ашлык ташыйлар. Зиннәт бу эшне тырышып башкара. Колхоз җитәкчеләре аның эшеннән бик канәгать. Бер көнне малай өенә арба төбендә бодай калдырып кайта.

— Менә, әни, бодай алып кайттым!

Билгеле, бу бодайга мохтаҗ түгел алар. Зиннәтнең әти-әнисе яхшы эш хакы алалар, мал-туар, кош-корт асрыйлар. Мәрьям апа исә улының бу эшен хуп күрә:

— Рәхмәт, улым, тавыкларга булыр,— ди.— Файдага ярый башладың,— дип тә өсти.

Мондый сүзләрдән канатланып, Зиннәт көн саен арба төбендә ашлык калдырып кайта башлый. Беркөнне бригадир моны күреп ала да бу хәлне Зиннәтнең әтисе Баязит абыйга җиткерә. Ничек инде коммунист кешенең улы колхоз малына кул суза?

Бригадир белән сөйләшүдән соң ата кеше улын бик каты кыздырырга дип өенә кайта.

— Зиннәт,— дип чакырып ала әтисе улын,— син колхозга булышасың икән. Бригадир үзеңне мактады әле. Тик менә арба төбендә ашлык алып кайткансың, улым. Кемнән сорап алдың син аны?

Малай чыннан да болай ярамаганын аңлап, кылган эше өчен газаплана башлаганда гына, әлеге сөйләшүне тыңлап торган Мәрьям апа «һөҗүмгә» ташлана.

— Син нәрсә, ул бригадирның үзен урлашмый дип беләсеңме әллә? Бер уч бодайдан колхоз ярлыланмас әле,— дип тезеп китә ул.— Син генә артык намуслы инде...

Баязит абый хатынына ничек кенә аңлатырга тырышса да, файдасы булмый. Зиннәт исә бу бәхәстән үзенчә нәтиҗә ясый.

Акча алмашынган елларда кайбер шуграк малайлар үзләрендә калган иске акча белән күзләре рәтләп күрмәгән карчык-корчыкларны алдап чикләвек, көнбагыш кебек нәрсәләр алгалыйлар. Зиннәт тә бу «уен»нан читтә калмый. Шундый «шуклыкларның» берсендә ул «эләгә». Кич белән әтисе өйдә чакта бер карчык иске 5 сумлык тотып өйгә килә. Малай мондый эшләрнең ярамаганын белә белүен, ләкин әтисе ачуланса, әнисе яклар әле дип өметләнә. Малай ялгышмый, зарланып килгән карчыкка Мәрьям апа шактый ямьсез сүзләр әйтеп чыгарып җибәрә. Зиннәт батыраеп:

— Юк, мин түгел, әти, ул әби мине кем беләндер бутый,— дип ялганлый.

Шулай Зиннәт алдашырга өйрәнеп китә.

Шундыйрак хәлләр гаиләдә бер-бер артлы кабатланып тора.

Ата белән ананың балага карата бер үк таләптә булмавы, ананың баласын бөтенләй урынсыз яклавы, малайның әле формалашып җитмәгән характерына йогынты ясамый калмый әлбәттә.

Зиннәт урта мәктәптә район үзәгендә торып укый башлагач, Мәрьям апаның улы турында «кайгырту-

лары» икеләтә арта. Өйдә Зиннәтне эшләтмиләр, чөнки ул ял итәргә кайткан. Шулай итеп, Зиннәт ялкаулыкка өйрәнә.

Әнисе аңа ризыклар белән бергә әтисеннән яшереп акча да биреп җибәрә:

— Ач йөри күрмә, үзеңне кара,— ди ана.

Малай әнисенең бу «яхшылыгына» да тиз иярләшә. Анда баргач акчаларга урын табыла. Иптәшләре алдында үзен егет итеп күрсәтәсе килә Зиннәтнең. Ул аракы эчкәли. Үзеннән өлкәнрәк яшьтәгеләр белән аралаша башлый.

Беренче тапкыр өйгә исереп кайтуын сизгәч, Баязит абый улы белән чын-чынлап сөйләшергә була. Ләкин бу юлы да Мәрьям апа каршы төшә. Ул гына да түгел, малаен иркәләп урынга яткыра.

Менә шулай үсә Мәрьям апаның Зиннәте, шундый шартларда характеры формалаша. Бервакыт Мәрьям апаларга керүемне хәтерлим. Баязит абый юк иде инде. Йөрәк авыруыннан бик иртә үлеп китте. Мин кергәндә Мәрьям апа ишек алдында утын ярып маташа иде.

— Әллә үзең генәме, Мәрьям апа?

— Зиннәт өйдә, ял итә иде әле.

Өйгә кердек. Карчыкның пөхтә итеп җыештырылган караватына аяк киемен дә салмыйча менеп, Зиннәт сузылып яткан. Китап укый.

Аңламаса аңламый икән шул инде кеше. Нихәл итәсең, ана сөте белән кермәсә... дип белми әйтмәгәннәрдер.

Карчык ашын өлгертеп тәлинкәләргә салды. Зиннәт шунда ук торып утырды да ашый башлады, ә үзе әнисенә дәште:

— Бар әле, тастымал китер!

Әнисе бер сүзсез акрын гына атлап тастымал китереп бирде. Ашап туюга, тәлинкәсен этеп куйды да, кабат караватка юнәлде.

Мәрьям апа хәзер картайган, элекке чәчрәп торган чаклары узган. Ай-һай зур анын ялгышы. Төзәтеп бул-

мый торган ялгыш. Ананың бүгенге хәле бик кызганыч. Бу юлы кайбер әрнүләрен дә әйтми түзә алмады Мәрьям апа. Улының туктаусыз эчүен, шуның аркасында эшсез калуын, документларын югалтуын, хәзер эшләмичә өйдә ятуын, эчәргә акча сорап тинтерәтүен, бирмәсә төрлечә куркытуларын — бөтенесен бәйнә-бәйнә сөйләде ул. Ләкин ул боларны улына әйтми, һаман ул аның кылган эшләрен кичерә килә, китсә кая барасын сорамый, кайтып керсә сүз әйтми, дөресрәге, курка ул аннан хәзер.

Әйе, Мәрьям апаның картлык көннәре бик күңелсез үтә. Ирексездән А. М. Макаренко сүзләре хәтергә килә: «...Безнең балаларыбыз — безнең картлыгыбыз. Дөрес тәрбия — бу безнең бәхетле картлыгыбыз, начар тәрбия — бу безнең киләчәк хәсрәтебез, безнең күз яшьләре, кешеләр алдындагы гаебебез...»

ИРТӘГӘ СОҢ БУЛЫР...

Гаепләнүчеләр эскәмиясенә эләккән яшүсмерләр еш кына үзләренең нәрсә эшләгәнлекләрен аңлап, аны бәяләп җиткермиләр. Кайдан килә мондый беркатлылык? Югыйсә шәхси җаваплылык хисе кешедә бик иртә формалаша башлый бит («ярый», «ярамый» дигән төшенчәләр сабый чактан ук үзләштерелә). Ләкин бу тойгының кешене ярамаган эшләрдән тыеп торырлык көчкә ия булуы өчен әйләнә-тирә мохитының (гаилә, мәктәп, коллектив һ. б.) актив булышлыгы кирәк. Тәрбия эшендә бер генә буынның йомшавы да үзен сиздерә — шәхеснең үсешенә тискәре йогынты ясый.

Түбәндәге язмада, конкрет мисалга таянып, минем менә шуны күрсәтәсем килә

— Ягез, тәвәккәлләдек! — диде Әлфия үзенең ахирәтләренә.— Кеше-кара ни дә булса абайлаганчы, без аны момент...

Алар тротуардан кызу-кызу атлап баручы кызны куып җиттеләр. Кинәт кызның кулындагы сумкасы юл читенә атылып барып төште, ул да булмады, икенче кул аның башындагы яулыгын алды. Кыз асфальтка егылды...

Бу вакыйга белән миңа Ленин район халык суды утырышында танышырга туры килде. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә — 14—16 яшьлек дүрт кыз. Ләкин эшләгән җинаятьләре шундый рәхимсез, хәтта моның кыз балалар тарафыннан эшләнүенә ышанасы да килми.

Әлфия, Света, Марина һәм Галя. Дүртесе дә сигез класс белем алганнар, бер урамнан. Барысын да ишек алды таныштырган, урам дуслаштырган. Аларны берберсенә якынайткан сыйфатлар, мөгаен, үзләрен мөстәкыйль итеп, олы кеше итеп тоярга омтылу булгандыр. Бусы үсмерләр өчен табигый хәл. Ләкин аны кем ничек күз алдына китерә бит. Әйтик, мөстәкыйльлек, Әлфия белән Светаның аңлавынча, игътибарны җәлеп итәрлек итеп бизәнүдән һәм һәр егет-җилбәзәкне үзенә гашыйк иттерүдән гыйбарәт. Галя исә мин-минлекне артыграк күрә. Ә Марина битараф: андый характер белән җил каян көчлерәк иссә, шул якка аварга мөмкин. Бу дүрт кызны бер үк интереслар, бер үк омтылышлар дуслаштыра. Бергәләп бер яки ике шешәне дә бушатсаң, бөтенләй дингез тубыктан була. (Аракы эчү аларның гадәтенә әйләнә.) Мондый «процедура» «кызыклы яңа эшләргә» рухландыра, кыюлык өстәгәндәй итә.

Көннәрдән бер көнне «дуслар» кичке мәктәптән укудан кайтып килүче Нина исемле бер кызны кыйныйлар. Сәбәбен болай аңлаталар: «Сухая Река ягына автобуста йөреп кайтырга дип барган идек. Безнең белән егетләр дә бар иде. Алар безне рәнҗеттеләр. Безнең кәеф бозылды. Үпкәләп кайтып киттек. Кайтып җитүгә, кемнедер кыйнап, ачуны аласы килде. Беренче очраган кешене кыйнарга булдык. Сылтавы булсын өчен башта 20 тиен акча сорадык...»

Компаниянең «үсеш юлы»ндагы беренче «кыю» адымы шул була. Берәү дә комачауламый, тыймый, араламый, ул тыныч һәм шома гына үтеп китә. Ә бер чирканчык алгач... Чираттагы «операция» планы да өлгерә...

Бусы Сәлимә дигән кызны «акылга утырту» була. Аны көпә-көндез урам уртасында тотып кыйныйлар.

Бервакыт Әлфия белән Света Сәлимәнең бер егет белән барганын күрәләр. Күз алдында кыланып барган була, әллә кем диярсең! Әлфиянең бөтен зәһәре йөзенә чыга. Һәм ул янындагы Светага болай дип пышылдый:

— Кара әле, хәтерендәме, ул бит безгә бер литр куярга булган иде. Теге вакытта, танцыда?

— Әйе, хәтерлим.

— Соң. Ул бит аны куймады?

— Юк.

— Исенә төшерим әле шуның. Акылга утырыр.

Һәм дөрестән дә, Сәлимәгә озак котәргә туры килми...

Мондый вакыйгалардан соң дус кызларның «даны» тарала. Восстание урамнарында, Ибраһимов проспекты тирәләрендә йөрүче яшьтәшләре аларны читләтеп узарга тырышалар. Бер дә юкка гына түгел.

...Менә алар — Әлфия, Света, Марина һәм Галя. Бүген алар эшләгән җинаятьләре өчен суд каршында җавап бирәчәкләр. Тик аларның үз-үзләрен тотышыннан үзләре кылган эшләрнең никадәрле җитди булуын аңлау да, үкенү дә сизелми. Буш, битараф күзләр. Кайчагында гына оятсыз ялтырап китәләр. Зәвык дигән нәрсәне белмичә бизәнеп-ясанып килгәннәр үзләре. Әйе, мондыйлар теләсә нинди рәхимсезлек эшләргә сәләтле. Әнә алар тыныч кына, бернинди дулкынланусыз үзләренең эшен җентекләп искә төшерәләр.

— Сумкасын, яулыгын тартып алдык... Мин аның документларын яндырдым. (Әлфия сөйли.)

— Ә сезгә нәрсә кирәк иде соң? (Судья соравы.)

— Берни дә кирәкми. Без бары тик ачу гына алдык. Үзебезне рәнҗеткәннәре өчен...

Менә шулай, тиктомалдан гына, күңел бушлыгыннан килеп чыккан рәхимсезлек икән бу.

Кешене кеше хәленә керә белү бизи һәм аны кеше итә. Ә ул башка берәүне кызгана белүдән башлана. Ә Әлфия, Светлана, Марина һәм Галя моны аңлаудан ерак торалар. Кайчан соң бу кызлар үзләренең самими хисләрен югалтырга өлгергәннәр?

Күренекле педагог В. А. Сухомлинский менә нәрсә дип яза: «Яхшы хисләр, эмоциональ культура — кешелеклелекнең үзәге. Әгәр яхшы хисләр бала вакытта тәрбияләнмәсә, аларны беркайчан да тәрбияли алмыйсың, чөнки чын кешелеклелек күңелдә иң беренче һәм иң әһәмиятле хакыйкатьне танып белү белән, туган телнең иң нечкә төсмерләрен тоя һәм кичерә белү белән бер үк вакытта ныгый... Балалык һәм үсмер чор яхшылык, кешелеклелек, игътибарлылык мәктәбенә әйләнергә тиеш. Шул чагында гына кеше йөрәгендә иң яхшы хисләрнең бөтен гаммасы булачак».

Ә безнең бу «геройлар»ның гаилә шартлары, әти-әниләре, коллективта үз-үзләрен тотышы белән танышу бөтенләй башка картинаны күз алдына китереп бастыра.

Әлфия. Өендә ул әнисе, үги әтисе белән яши. Аларны санламый, бернәрсәне дә алар белән киңәшеп эшләми. Әнисе дә, үги әтисе дә шешә белән дус. Ата-ана белән кыз арасында тупас ызгышлар әледән-әле кабатланып тора. Мәктәптә Әлфия иң начар укучылардан саналып килә. Бик еш дәрес калдыруы, ялганлавы белән укытучыларның үзәгенә үтә. Әлфия 14 яшеннән аракының тәмен татый, тәмәке тартырга өйрәнә. Сигезенчедә укыган җиреннән Женя исемле берәүгә кияүгә чыга. Женясы җавапка тартылгач, артык борчылмыйча гына, кире өенә кайта. Өлкәннәр тормышының тагын бер серле ягы ачыла аңа. Беренче тәэсирләр һәрвакыт көчле була. Аларны кем беләндер уртаклашмыйча мөмкин түгел. Мәктәптә аның дуслары юк. (Әлфия андагы иптәшләрен сабыйлар

дип саный.) Ә теге кызлар (Света, Марина, Галя) аңлыйлар. Аларга барысын да сөйләргә була...

VIII классны тәмамлатырга да котылырга! Мәктәптә менә шуңа омтылганнар, сигезне ничек кирәк алай тәмамлауга, аны балигъ булмаган яшьләр белән эшләү комиссиясе ярдәмендә күн производство берләшмәсенә эшкә урнаштыралар. Ләкин Әлфия анда да мәшәкать арты мәшәкать тудыра. Остаз итеп билгеләнгән өлкән эшче дә үзе әйткәнчә, «аны тәрбияләүдә уңышка ирешә алмаган».

Дүрт кыздан торган компаниянең терәге Әлфия менә шундый.

Сүз дә юк, Әлфия һәм аның кебек тәрбиягә авыр бирелә торган яшүсмерләрнең күңеленә үтеп керү җиңел эш түгел һәм бөтен кыенлык шунда: гадәти үсмергә яраган ачкыч боларга ярамый. Тәрбия эше белән турыдан-туры шөгыльләнүче, шуның буенча махсус белем алган кешеләр моны истән чыгарырга тиеш түгел. Бәлки, класс җитәкчесенең Әлфия белән ачыктан-ачык сөйләшүе кирәк булгандыр. Әйтик, балигъ булмаган килеш ярәшү һәм аның кыз баланың киләчәк язмышы өчен никадәр зарарлы булуы турында. Битәрләп түгел, яшүсмер кыз күңеленә үтеп керерлек итеп, дустанә сөйләшергә.

Әлфияне дөрес юлга бастыру буенча күрелгән чаралар арасында нәкъ менә шундый гади генә, кешеләрчә эчкерсез сөйләшү җитмәгән. Ә бит Әлфия һәм аның кебекләр җылы сүзгә, аналарча яхшы теләктән әйтелгән сүзгә бик мохтаҗ. Тумыштан ук тоташ яхшы яки тоташ начар кешеләр булмый. Тормышта кешене яхшы яки начар итә торган сәбәпләр була.

Менә Әлфиянең беренче ахирәте — Света. Әтисе хөкемгә тартылган, әнисе эчкече. Шунлыктан әбисе тәрбиясендә тора. Мәктәптә дус кызлары юк, берәү белән дә аралашмый. Әлфия белән дуслашуына бик канәгать. Ул аны «мине аңлаучы бердәнбер дустым» дип саный. Әлфия — Света өчен иң югары авторитет. Ул аның кебек

булырга тырыша. Өйдә әбисе белән көнкүреш мәсьәләләреннән башка темага сөйләшми. Укырга яратканы — маҗаралы китаплар.

Марина. Әнисе белән генә тора. Әтисе гаиләсен ташлап киткән. Әнисен кызгана, ләкин эчке дөньясын аның белән уртаклашмый. Бер заводның фабрика-кухнясында эшли. Өйдә үзен әйбәт тота. Әнисе аны «иптәш кызлары бозды» дип саный.

Галя. Әти-әнисе күптән инде кыздан кул селтәгән. Бер сүзләрен дә тыңламый, һәрнәрсәдә үзенең алардан «өстен» булуын исбатларга тырыша. «Теләсә нинди дуамаллыкны көтеп була»,— ди әнисе аның турында.

Күргәнебезчә, теге яки бу сәбәпләр аркасында әлеге гаиләләрнең берсендә дә ата-ана белән бала арасында җылы мөнәсәбәт, фикер уртаклыгы калмаган. Ә бит бу яшьтә ачылмаган серләр, сорыйсы, киңәшәсе нәрсәләр никадәр? Мәктәптә аңлашырдай кеше юк... Әти-әни киңәшче була алмый. Бер генә юл кала: андый кешене читтән эзләргә...

СССР Конституциясендә менә мондый юллар бар: «СССР гражданнары балалар тәрбияләү турында кайгыртырга, аларны җәмгыятькә файдалы хезмәткә әзерләргә, социалистик җәмгыятьнең лаеклы членнары итеп үстерергә бурычлы». Моны уңышлы хәл итү өчен, беренче чиратта, ата-ананың үз-үзенә таләпчәнлеген арттырырга кирәк.

Ә инде тәрбия методың баланы кимсетүдән узмаса, аның белән уртак тел табу турында сүз дә булуы мөмкин түгел.

Әлфия һәм аның әти-әнисе арасындагы конфликт төенен чишүе кыенрак булыр, ләкин балалары әле җинаять юлына басмаган башка ата-аналарны кисәтәсе килә. Балаларыбыз безне ни өчен тыңларга, хөрмәт итәргә тиеш? Ата-ана булган өчен генәме, әллә?.. Үз тормышыбыз белән, кешеләр арасында тоткан урыныбыз белән без аларны нәрсәгә өйрәтәбез? Нинди үрнәк бирәбез?

Алдагы тормышы, мөстәкыйль тормышы өчен мирас итеп ул бездән нинди сыйфатларны ала? Бала өчен болар барыбер түгел. Шуңа күрә бу хакта уйланырга кирәк, мөмкин кадәр иртәрәк уйланырга кирәк. Юкса соң булуы бар.

БЕР УРАМ МАЛАЙЛАРЫ

Кинодан кайтып килгәндә үз ишекләре янына сөяп куелган өр-яңа «Тисса» мопедын күргәч, Рөстәмнең башы күккә тия язды. «Кемнеке микән бу?»— дип уйлады малай. Мопедның әле бер, әле икенче җирен капшап карады. Һәммә нәрсәсе үз урынында. Бер утырып урамнарны иңлисе иде дә бит! Белмәгән килеш ярамас шул.

Ул шулай мопед тирәсендә бөтерелгәндә, баскычтан менеп килүче Юра күренде.

— Һәйбәт нәрсә бит, ә? — диде Юра Рөстәмне күрүгә.— Әллә, бер әйләнеп килобезме?

Рөстәмнең шатлыгы йөзенә чыккан иде. Ул мопедка утырып бер генә түгел, ике-өч әйләнде.

— Мин аны сиңа бүләк итәм,— диде Юра.

— Җир астыннан булса да табып бирәм дигән идемме?

— Ә син аны кайдан алдың?

— Тсс, шаулама!

Аннары Рөстәмнең колагына пышылдап кына:

— Чәлдек без аны, синең өчен! — диде.— Берәү дә күрмәде, тыныч бул.

Бу соңгы сүз Рөстәмне шомландырган иде дә, ләкин мопедта йөрү шатлыгы аны тиз онытырды.

Әмма бу шатлык озакка бармады. Бер көнне милиционер формасындагы ике кеше Рөстәмнәргә килеп мопед белән кызыксындылар. Аны карадылар, тикшерделәр, нидер язып алдылар, сораштырдылар. Аннары, унөч

яшьлек Рөстәмне шаһит сыйфатында милициягә чакыртырга булып, китеп бардылар.

...Ленин район халык судында биш егетнең, дөресрәге, егет булып җитәргә әле өлгермәгән биш яшүсмернең эше каралды. Юрий Порфирьев, Олег Бугров, Сережа Колоколов, Игорь Коляканов, Сергей Кукушкин... Бер урам малайлары, күбесе бер мәктәптә укыганнар. Бүген исә алар гаепләнүчеләр эскәмиясендә. Бу яшүсмерләр урлаган әйберләрнең исемлеге шактый озын. «Минск» маркалы мотоцикл, «Электрон», «Восход-2» мотороллерлары, «Ява-350», «Турист» һәм, ниһаять, әлеге «Тисса» мопеды. Моның өстенә, әле алар Короленко һәм Гагарин урамнары почмагындагы азык-төлек киоскысын басканнар. Аннан урланган әйберләр 309 сум 91 тиенгә җыела.

Урлашу. Бүген бу сүз сәеррәк яңгырый сыман. Элекке авыр елларда мохтаҗлыктан урлашырга мәҗбүр булган яшүсмерләр турында беләбез. Ә бүгенге яшүсмерне — өстенә шәп куртка кигән, кулына транзистор тоткан яшүсмерне моңа нәрсә этәрә соң? Биредә утыручы яшүсмерләрнең һәркайсының әти-әнисе бар, әйбәт хезмәт хакы алып эшлиләр. Барысы да бөтен уңайлыклары булган квартираларда яшиләр. Яшүсмерләрнең кайберләре стипендия ала, эшләүчеләре дә бар. Димәк, нәрсәгә дә булса мохтаҗлык турында сүз булуы да мөмкин түгел. Ә бәлки, җавапсызлыктыр, җиңел тормышка омтылудыр?

Суд залында утырганда мин шул сорауларга җавап эзләдем һәм җинаять юлына баскан яшүсмерләрнең әле башланып кына килә торган биографияләрендә бер генә детальне дә күздән ычкындырмаска тырыштым.

Менә Юра Порфирьев. 29 нчы профтехучилище укучысы. Урлашуда башлап йөрүчеләрнең берсе. Училищеда мотоцикл йөртергә өйрәнгән, ләкин мотоцикл йөртү өчен таныклыгы юк. Малайларны ул котырткан. Тегеләре исә һич икеләнүсез аның тәкъдимен кабул иткәннәр.

Гараж ишеген вату яисә йозак ачу кебек алымнарны Юрадан да шәбрәк белүче, мөгаен, булмагандыр. Яисә Олег Бугровны алыйк. 30 нчы профтехучилище укучысы ул. Унбер яшеннән милициянең балалар бүлмәсендә учетта тора. 13 яшьтән тәмәке тарта. Мәктәптә укыганда яшьтәш малайларын куркытып, акча сорап ала. Икенче тапкыр җавапка тартылуы.

7 нче мәктәп укучысы Игорь Коляканов — уникe яшеннән, 29 нчы профтехучилище укучысы Сережа Колоколов унбер яшеннән милициянең балалар бүлмәсендә учетта торганнар.

Ремонт-механика заводында эшләүче Сережа Кукушкинның да биографиясе иптәшләренекеннән әллә ни аерылмый.

Беренче карашка бу малайларның кыяфәтендә тискәре бәя бирерлек бер генә сыйфат та тапмыйсың. Судьяның сорауларына алар берни яшермичә, дөрес җавап бирәләр, эшнең ничек булганын бәйнә-бәйнә сөйлиләр.

Судья: «Ни өчен урлаштыгыз?»— дип сорый.

— Юләрлек белән иде. Бик тә мотоциклда йөрисе килгән иде шул. Прокатка бирмиләр. Чөнки таныклыгым юк. Бүтән кабатланмас. Киләчәктә намус белән эшләрмен...

Олег шулай ди. Калганнарының да җаваплары шундыйрак. Малайларның йөзләрендә үкенү дә, борчылу да бар. Шулай да... Бу җавап укытучы сораганда дәресен белмәгән укучы җавабын күбрәк хәтерләтә. Җиңел әйтелгән сүзләр, гадәттә, шулай җиңел генә онытылучан да була. Әгәр үсмер үзенең никадәр зур җинаять эшләгәнлеген аңлап, аны йөрәге аша кичереп газапланмый икән, мондый сүзләр коры вәгъдә булып калудан узмый шул. Яшүсмерләрне тыелган чикне үтеп чыгарга — җинаять ясарга этәргән сәбәпләрнең берсе нәкъ менә үсмернең үзе кылган эшкә бәя бирә белмәвендә түгел микән? «Болай эшләргә ярамый, бүтән кабатланмасмы?» Бер-бер ярамаган эш эшләгән очракта еш кына өлкәннәр

балага яки үсмерләргә шулай диләр. Әмма бу сүзләр үсмернең бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга. Дөрес, үзе өчен күңелсез әңгәмәдән тизрәк котылу өчен бала, әлбәттә, «юк, бүтән кабатламам» ди. Сөйләшү исә шунда ук онытыла да. Ә бит иң мөһиме — ялгыш адымы яшүсмернең яки баланың аңына барып җитсен, ул бу эшнең ни өчен ярамаганлыгына төшенсен. Моңа үгет-нәсихәт белән түгел, ә бәлки шәхескә үз-үзе белән көрәшү мөмкинлеген тудырганда гына ирешеп була.

Суд каршында җавап тотучы үсмерләр язмышына кабат кайтыйк. Мәктәптән бирелгән характеристикаларына караганда, алар барысы да начар уку, тәртип бозу, гамьсезлек, пассивлык белән аерылып торалар. Тик бер нәрсәгә игътибар итик: бу характеристикалар суд таләп итүе буенча язылган. Ә аңа кадәр, мәктәпне тәмамлап киткәндә бирелгән характеристикалар аларны уңай яктан күрсәтә. Бу малайларга бик яшьли милициянең балалар бүлмәсе бусагасын таптарга туры килгәнлеген әйткән идем инде. Бу бүлмәгә аларны нәрсә китергән? Мәсәлән, Сережа Колоколов «урамда узган-барган кешеләргә таш ыргыткан өчен», Олег Бугров «кешеләрдән акча теләнеп алган һәм өеннән китеп йөргән өчен» учетта торган. Бу эшләр балигъ булмаган яшьләр белән эшләү комиссияләрендә күп тапкырлар тикшерелгән дә. Ләкин берниди нәтиҗә дә бирмәгән әлеге сөйләшүләрнең ниндирәк эчтәлектә булганлыгын чамалау кыен түгел.

Судта, мәсәлән, Юраның әтисе малаена бик коры булуын, улының үзеннән куркып торуын сөйли. Ләкин мондый куркыту яки тыюга корылган мөнәсәбәтләрнең ата белән улы арасында нинди дә булса рухи уртаклык тудыра алуы бик шикләндерә.

Үсмерчакта кеше тыштан караганда ничек кенә мөстәкыйль булырга тырышмасын, ул әле өлкәннәр ярдәменә, аларның акыллы киңәшенә бик мохтаҗ. Ул ташып торган энергиясен файдалы эшкә юнәлтә белерлек, аны ялгыш адымнардан саклап кала алырлык остазга мох-

таҗ. Шулай булмаганда, яшүсмер кешеләр арасында да үзен ялгыз дип хис итәргә мөмкин. Бу исә аның өчен куркыныч. Дөрес, Юрага да, Олегка да, бүген гаепләнүчеләр эскәмиясендә утырган башка яшүсмерләргә дә остазлар билгеләнгән булган. Алар судта үзләре дә чыгыш ясадылар. Тик шунысы аяныч, аларның берсе генә дә бу малайларның күңелендә ниләр ятканын белә алмаган.

Ни өчен? Танылган педагог В. Сухомлинскийның:

«Тәрбиянең бөтен бәласе тәрбияче белән тәрбияләнүче арасында рухи уртаклык булмауда... Тәрбияче яшүсмернең күңелендә ниләр барын сизенергә тиеш... Шул ук хисләрне кичерүче, шул ук идеяләр, иҗтимагый интереслар белән яшәүче, шул ук кыйммәтләр белән мавыгучы, яшүсмер әзләгән нәрсәне үк кызыксынып эзләүче кеше генә яшүсмернең остазына әверелә ала»,— дигән сүзләре бу сорауга җавап булып яңгырый. Күрәсең, әлеге яшүсмерләрнең остазларына әнә шулар җитмәгән.

...Озакка сузылган, ялыктыргыч суд процессы тәмамлангач, без, залда утыручылар, урамга, саф һавага чыктык. Ләкин күңел кабат-кабат әлеге яшүсмерләр язмышына кайта. Әйе, алар бу «эш»тән сабак алганнардыр. Тик соңгарак калып. Ә менә судта шаһит рәвешендә катнашкан Рөстәм өчен, әле кайчан гына Юра һәм Олег кебек малайларның «кыюлыгы»на сокланып караган Рөстәм өчен бу сабак бик вакытлы булды. Һәм ул, мөгаен, моны беркайчан онытмас.

ӘТИЛӘР ТУРЫНДА ХАТЛАР

Беренче хат

...Без синең белән ничектер көтмәгәндә якынаеп киттек, Зөлфия. Хәтерлисеңдер, син мине озатканда башланган сүзебезне хат аша дәвам иттерергә булган идек.

Ул сүз әтиләр турында иде. «Әти дигән сүз телеңнән төшми. Кыз бала да шулай ата җанлы булыр икән!» дидең син. Һәм, кызыксынып, минем әтиемнеңниндирәк кеше булуы турында сөйләвемне үтендең. Шуннан соң мин уйланып йөрдем. Шулай бит ул, үзең өчен гадәти тоелган әйберләрне сөйләргә теләсәң, кайдан тотынырга белми аптырыйсың.

Беркөн минем янга идарәгә Мәүгыйдә әби килеп керде. Гадәтенчә, җылы итеп исәнләште, хәлләрне, әткәй-әнкәйләрне сорашты. Аннары үзе турында да сөйләде. Күпне күргән карчык. Сугышның беренче көннәрендә үк тол калган. Гомер буе балаларын ялгызы карап үстергән. Хәзер ул урын өстендә ятучы йөз яшьлек әнисен карый. Менә шул Мәүгыйдә әби әткәйне бик мактады.

— Галимҗан үзебезнеке инде ул,— дип, әткәй белән әнкәй турында озаклап сөйләде. Элегрәк идарәдә дежур торганда (без бәләкәй чакта) ул кайтышлый гел безгә керә торган булган. Әткәй аңа: «Мәүгыйдә апа, кайтып йөрмә, бездә генә кал»,— ди торган булган. «Кайчан гына барып керсәм дә һәрвакыт сездә кунак булып чыга идем, ә бит әле ул авыр еллар иде, үзегез дә ишле»,— дип сөйли Мәүгыйдә әби.

Үзебезнең районлагы авылларның күбесендә әткәйне беләләр. Кайчак мине берәрсе туктата да: «Син Галләмов Галимҗан кызымы әллә? Бигрәк ошагансың»,— дип сораштыра башлый. Белеп торам, әткәйне хөрмәт иткәнгә күрә шулай диләр.

Әткәй егет чагында сугышта катнашкан. Фронттан кайтканнан бирле ул үзебезнең «Чишмә» колхозында механик булып эшли. Безнең авылда, санасаң, әткәйнең ярдәме тимәгән кеше сирәктер. Кайдадыр берәр техника сафтан чыкса, әткәйгә киләләр. Ул кырык эше кырылып ятса да кешене ярдәмсез җибәрми. Безнең колхозның терлекчелек фермасындагы бөтен механизация әткәй кулы белән эшләнгән. Әткәйнең рәсеме күп еллардан бирле колхозның Почет тактасында.

Өйдә дә әткәй булышмаган эш юк. Безнең гаилә ишле: сигез бала, хуҗалык зур, мал-туар да асрыйсың. Күпме су ташырга кирәк. Ә суны тау астындагы коедан ташый идек. Әткәй шуңа борчылып йөргән икән. Беркөнне насос алып кайтып куйды. Хәзер суны насос ярдәмендә күтәртәбез генә. Менә шулай безнең әткәй колхозда булмасын, өйдә булмасын, авыр хезмәтне җиңеләйтү юлларын эзләп таба тора. Әткәйнең эшсез торган чагын беребезнең дә күргәне юк. Безнең өйдә шулай гадәтләнелгән — берәү дә эшсез тора алмый. Апалар, абыйлар кунакка гына кайткан арада да өйдә әллә никадәр эш эшләп китәләр. Ижевскидагы абыйлар ялларын бәрәңге алган вакытка туры китерергә тырышалар. Әткәй-әнкәй йортына кайту безнең һәркайсыбыз өчен зур бәйрәм. Әткәй безнең барыбызның да эше, тормышы белән кызыксына. Тик ул бу хакта төпченеп сорашмый. Ничектер аңа барысын үзең сөйләп бирәсең. Чөнки аның теләсә кайчан хәлеңә керергә әзер торуын беләсең.

Әткәйнең төрле яшьтәге бала-чага белән дә сөйләшер сүзе бар. Ул ничек кенә арыган яки кәефсез булмасын, бала-чаганы очратса, шаяртып, алар белән гәп корып ала. Әнкәйнең туган энесе Әбелгавис абзыйның дүрт яшьлек улы Илмар әткәй өчен үлеп тора.

Беркөн урамда трактор тавышы ишетелә икән. Илмар:

— Җизни тракторы тырылдый. Хәзер килеп җитә. Бәлешне җизнигә дә калдырыгыз! — ди икән.

Кайбер кызлар әтиләре янында артык сөйләшмиләр, бик үк ачылып та китмиләр. Минем өчен әткәй янында аеруча рәхәт. Тормышта берәр мәсьәләне хәл итәргә икеләнсәм дә, эшемдә бер-бер кыенлык килеп туса да мин башлап әткәй белән киңәшәм. Аның белән бер әңгәмә корып алу гына да үзе бер гомер.

Колхоз комсомол оешмасына секретарь итеп сайлангач куркыбрак калдым: эшли алырмын микән? Кайтып

керүгә, икеләнүемне эткәй йөземә карауга ук сизде, ахры, сорап куйды:

— Нәрсә, кызым, бер-бер хәл булдымы әллә?

Хәлләрем турында сөйләп бирдем.

— Кайгырма, кызым, барысы да әйбәт булыр,— диде ул.— Кайда кушсалар шунда эшлә, өйрәнерсең. Кыенга килсә, тартынма, әйт, кулдан килгән кадәр мин дә булышырмын.

Берничә көннән үк клубта спортзал җиһазлау буенча комсомол өмәсе оештырырга булдык. Әткәй техника белән дә, кешеләр белән дә ярдәм итте. Өмә бик җанлы үтте. Хәзер күпме егетләребез шул спортзалга йөри.

Быел мине райкомга чакырдылар. Комсомол райкомына инструктор итеп тәкъдим итмәкчеләр иде. Гадәтемчә, әткәй белән кайтып киңәшләштем. Ул аз гына уйланып торды да:

— Кызым, колхозда, бу эшеңдә үзеңне күрсәтеп өлгермәдең бит әле,— диде.— Районга, инструктор табылыр анысы, тик башта авылда, туган колхозыңда ныклап эшләп күрсәтсәң, минемчә, яхшырак булыр. Дөрес, мин сине көчләмим, үзеңә кара, уйла, мин сиңа үз фикеремне генә әйтүем.

Миңа шул гына кирәк иде, болай да икеләнеп кайткан идем.

Мин сиңа бер яңалыгымны әйтмәдем бит әле, Зөлфия. Әле күптән түгел тормышка чыктым. Ирем авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаган кеше, Уфа авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укый. Ул фермада зоотехник. Әткәй хәзер безнең икебез өчен дә борчыла, һәр адымыбыз белән кызыксына. Кызыксынуы да үзенчә аның. Ул бик җайлы гына, иплән кенә сораштыра белә. «Кияү яки кызым, шул эшегезне эшли алдыгызмы, барып чыктымы, ярдәм-мазар кирәк түгелме?» Әткәйнең тынгысызлыгына, ару-талуны белмәвенә, сабырлыгына мин кайчак хәйран калам.

Узган ел әнкәебез егылып аркасын авырттырды. Ай

буе больницада ятты. Иртән торуга әткәй иң беренче булып шул хакта кайгырта башлый:

— Балалар, бүген әниегезгә нәрсә алып барыйк икән? Больницада көннәр озын була, борчылырлык булмасын, күңеленә ошардай берәр нәрсә әмәллик.

Көн саен шулай. Бер дә иренмичә, төрле-төрле тәмле ризык әзерлибез дә әнкәй янына барабыз. Әткәй белән бергә безгә күңелле, арыганнар онытыла...

Минем еш кына шул хакта уйланганым бар: безнең әткәй ачулана беләме, дим, без аннан куркабызмы икән? Юк, шушы яшемә җитеп минем әткәйнең ачулы йөзен күргәнем булмады. Нәрсәгәдер хәтере калганда да ул ачу чыгармый, бары тик бераз җитдиләнеп кенә китә. Абыйларым, энеләрем дә шулай ди. Шундый әйбәт кешедән куркалармыни? Әмма аның ышанычын аклый алмау безне нык куркытыр, хурландырыр иде.

Беркөнне Камил абый да шул хакта әйтте:

— Бала вакытта ук мин әткәйнең бер сүзеннән курка идем,— ди. «Ярар, улым, булмаса үзем эшләрмен». Әткәйнең шул сүзе үтерә дә сала иде. Шуны әйттермәс өчен генә дә мин әллә нәрсәләр эшләргә риза. Бу сүз минем өчен каты итеп яңаклаудан да авыррак... Хатым озынга китте. Әткәй характерын, аның безнең өчен ни дәрәҗәдә кадерле булуын аңлата алганмындырмы, белмим. Тик шуны гына әйтми кала алмыйм, минем ирем дә әткәйгә бераз охшаса, бик бәхетле булыр идем.

Фәридә.

Актаныш районы.

Икенче хат

Рәйханә апа! Сез миңа язган хатыгызда үзем турында сөйләвемне үтенәсез. Әйе, мин хат аша бик иркенләп сөйли алам. Ә үзегезгә мөгаен берни дә әйтә алмаган булыр идем...

Мине сәер кыз дип йөртәләр. Минем күңелем түрендәниләр барын иптәш кызларым да белми. Алар алдында мин шаярам, көләм, җилбәзәк кыз булып кыланам. Тик болар барысы да битлек кенә.

...Чын бәхетле булу өчен әти-әниең белән горурланырга кирәктер ул. Ә мин горурлана аламмы соң? Юк. Әнием хакында бер генә яман сүз дә әйтә алмыйм. Ә менә әтине «әти» дип атарга тел бармый. Мин аларның үз балалары түгел. Үз әнием мин дөньяга килгәч үк үлгән. Ике яшемдә мин Уфада балалар больницасына эләккәнмен. Шунда ук хәзерге әниемнең дә өч яшьлек улы, абыем Илдар яткан. Без аның белән дуслашып киткәнбез. Әни һәр килүендә безне бергә чакыртып ала торган булган. Ул улын алып кайтырга җыенгач, мин елаганмын, больница коридорында алар артыннан йөгергәнмен. Шуннан әни мине дә үзе белән алып китәргә булган...

Мин ятимлекне сизмәдем. Әтидән зарлануым да алар үземнеке булмаган өчен түгел. Бервакыт күрше карчыгы үземне чакырып алып серне чишмәгән булса, мин бу хәлләрне белмәгән дә булыр идем. Ләкин мин хәзерге әтием йортында яшәүдән ятимлекне артыграк күрәм. Бернәрсәгә үкенәм: ник миңа әти булып әйбәтрәк кеше очрамады икән. Ата-ананы балалар сайлап ала алмый алуын. Тик бит язмыш андый мөмкинлекне куйган.

...Беренче класста укып йөргән чагым иде. Математикадан «5»ле алдым. Канатланып, очып диярлек өйгә кайттым. Әти өйдә. Тизрәк көндәлегемне алып әтигә суздым. Карар, минем белән бергә шатланыр дип көттем. Ә ул кырыс кына итеп:

— Бар әле, синең көндәлегеңнән башка да эшем җитәрлек,— дип кулын гына селтәде. Аңа көндәлек сузган кулым һавада асылынып калды...

Мәктәптә кызлар әтиләре турында сөйлиләр. Берсе әтисе белән шәһәргә барган, икенчесенә әтисе бик матур курчак алып кайткан, өченчесенә әтисе мәсьәлә чишеш-

кән. Алар арасында мин нәүмизләнеп басып торам. Минем әти турында сөйләр сүзем юк.

Балачакта мондый хәлләрне аеруча авыр кичерәсең, кимсенәсең. Ун ел мәктәптә укып әти ичмасам ник бер генә тапкыр минем ничегрәк укуым белән кызыксынсын. Ник бер генә тапкыр көндәлегемне кулына алып карасын. Ата-аналар җыелышына да йөрми иде ул. Мин әтиләре белән янәшә атлап баручы кызлардан, малайлардан көнләшә идем. Шундый әтиләр дә була икән дип кызыгып карап тора идем.

Еш кына әти «салгалап» кайта һәм бер сәбәпсез әнигә бәйләнә башлый. Усә төшкәч мин әнине яклап берәр сүз әйтсәм, икебезгә дә көн бетә. Андый вакытта өйдә йоклый алмыйсың инде. Күршеләрдә куныш чыгабыз...

Мин китаплар укырга, җырларга яратам. Ә әти укып утырганымны күрүгә, кычкыра башлый:

— Нәрсә, эшең беттеме әллә? Барасың да китапка багынасың?!

— Мин инде эшләремне бетердем.

— Кыз баланың эше бетәмени...

Шуннан инде синең китап уку түгел, үз-үзеңне кулга алырлык та чамаң калмый. Ирексездән күздән яшь ага башлый.

Бервакыт мин өйдән чыгып китәргә дә җыенган идем. Әнине кызганып калдым.

Тора-бара мин үзем дә аның белән әйткәләшергә өйрәндем. Нишлисең, дәшмәгән саен ул азына. Шуңадыр, мин усалландым. Ул бер сүз әйтсә, мин бишне...

Аның шундый ваемсыз, таш бәгырьле холкы мине тормыштагы күп нәрсәләрдән мәхрүм итте. Урта мәктәпне тәмамлаганда мине бөтен иптәшләрем, укытучыларым консерваториягә барырга димләделәр. Мәктәптә оештырылган үзешчән сәнгать түгәрәгендә мин башлап йөрүчеләрдән идем. Концертларның берсе дә миннән башка үтми. Өйгә кайтып мин хыялымны әнигә сөйләдем. Әни белән безнең сөйләшүне тыңлап торган әти шунда ук кырт кистереп болай диде:

— Нәрсә, тагын минем җилкәдә укырга җыенасыңмы? Кайчан үзең акча эшли башлыйсын инде?

— Курыкма, мин үзем эшләп укырмын...

Тагын каһәрләүләр, тагын күз яшьләре. Бөтенесенә кул селтәдем дә төзелешкә китеп бардым. Менә шулай итеп ул минем хыял канатларымны да каерды.

Хәзер мин еш кына үземнең балачагымны искә төшерәм дә, әниемнең мине алып кайтып киткән көнен каһәрлим. Билгеле, әнигә үпкәм юк. Ул йөрәге кушканча эшләгәндер. Ләкин шулай да мин андый әти белән яшәүдән балалар йортында үсүне артыграк күрер идем.

Хәзер мин төзелештә эшлим, тулай торакта яшим, үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөрим. Ләкин күңелем китек. Тик бу хакта берәүгә дә сөйли алмыйм. Атаңны яманлап кешегә сөйләве җиңел түгел бит ул...

Мәдинә.
Түбән Кама шәһәре.

ӘНИ СҮЗЕ

(Төпчек кыз көндәлегеннән)

Ана. Исәпләсәң, җир йөзендә күпме аналар бар. Аларның бөтенесен бер нәрсә берләштерә — баласына тирән мәхәббәт хисе. Аналарны, гадәттә, кояшка тиңлиләр. Бары тик ана кеше генә, кояш кебек, мәхәббәтен балаларына тигез бүлә белә. «Бармакның кайсын тешләсәң дә авырта»,— дия идең син. Мин ул сүзне синнән бик еш ишетә идем, әни. Менә хәзер сине, сине һәм безне үстергән, күңелгә табигатьнең иң матур почмагы булып сеңеп калган туган авылымны искә төшереп утырам. Саба районының нәни генә бер авылы ул. Сабай дип йөртәләр. «Бәйрәмовлар кайда тора»,— дип сорасалар, безнең йортны теләсә кем күрсәтер. Ун балалы гаиләләр авылда икәү генә.

10 ноябрь

Киткәнемә әле күп гомер узмады, шулай да сине сагынырга өлгердем, әнием. Әниләрне яратуны өйдә чакта артык сиздереп тә булмый. Ә аралар ерагайгач бөтенләй башкача икән. Биредә, синнән еракта чакта мин күңелем белән сиңа бик еш әйләнеп кайтам, серләремне синең белән уртаклашам, адымнарымны сиңа карап үлчим. Синең сүзләреңнең мәгънәсен мин хәзер тагын да тирәнрәк аңлыйм кебек.

Бервакыт миңа бер кичәдә булырга туры килде. Бик матур гына башланды ул. Уен-җыр, төрле өннәләр. Күңелдә әйбәт, җылы тәэсир калды дип кенә торганда, берничә кызның үз-үзләрен тотышын күреп кәефем китте. Шунысы аяныч: мин алар арасында үзебезнең курсташыбызның берсен күрдем. Ул кызны имтиханнар бирен йөргәндә беренче тапкыр очраткан идем. Ул да беренче адымнарын кыюсыз гына атлаган иде. Әйбәт дуслар очратырга хыяллануы турында сөйләде. Мин аның белән дуслашырга әзер идем. Ләкин шул хакта ышандырырлык итеп әйтә алмаганмындыр.

Имтиханнар тәмамланып, укулар башлангач, ничектер мин аны күздән югалттым. Һәм менә шул кичәдә аның ни өчен югалып йөрүе аңлашылды кебек. Менә нинди «дусларга» юлыккан икән ул. Бу кызлар исерткеч эчемлек эчкәннәр иде, һәркемнең күзенә бәрелеп торырлык итеп бизәнгәннәр. Биегәндә дә алар үзләрен бик әдәпсез тоттылар, телләреннән тупас сүзләр дә ычкынгалады. Алар өчен мин оялдым, әнием. Ул гына да түгел, теге чакта активлык күрсәтә алмавыма үз-үземне битәрләп тә алдым. Син бит, әнием, әйтә идең, кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, дип. Синең ул сүзләреңнең мәгънәсенә мин ныграк төшендем хәзер.

20 декабрь

Нәни чакта без шулай дия идек. Хәзер дә таныш белешләрем, дусларым миннән еш кына: «Әниең кем синең?»— дип сораштыралар. Мин аларга:

— Минем әни гади генә кеше,— дип җавап бирәм. Ә үземнең күз алдымда — синең ягымлы йөзең, беркайчан да эштән бушамый торган тынгысыз кулларың. Юк, мин кешеләргә сине гади кеше дисәм дә, күңелемнән моның белән килешә алмыйм. Ун бала тәрбияләп үстергән ана ничек инде гади кеше булсын! Синең Герой-ана дигән мактаулы исемең бар, әнием. Ун баланы кеше итүнең кыенлыгын син үзең генә беләсең. Без синең авызыңнан беркайчан да зарлану сүзен ишетмәдек. Син үзең авыр тормышта үскәнсең. Укырга теләгең бик зур булса да, тормыш авырлыгы сиңа комачаулаган. «Күрше авылдагы мәктәпкә йөреп укырга аяк киемем юк иде»,— дип искә ала идең балачагыңны, әнием. Ә бит үзең шундй сәләтле булгансың. 1 нче класстан сине туп-туры 3 нчегә күчергәннәр. «Мин укый алмаганны сез укыгыз, кеше булыгыз»,— дигән сүзләрне безгә син кабатлый идең. Синең сүзне тотып, апамнарның дүртесе Ленин укыган университетны тәмамлады. Ниһаять, менә мин, төпчегең, шул университетта белем алам. Беребез дә беркайчан синең йөзгә кызыллык китермәдек кебек. Син үзең шулай дисең бит, әнием.

Мин үземне белә-белгәннән бирле син балаларыңның шатлыгына сөенеп, аларның аз гына борчуына да көенеп яшисең. Ләкин син көенечеңне сүзләр белән әйткәнең юк. Без аны синең күз карашыңнан укырга өйрәндек. Бервакыт Нургали абыйдан озак кына хат килми торды. Син эштән кайтып керүгә иң элек: «Хат юкмы?» — дип сорый идең. «Юк»,— дигәч, үзең бер сүз дә дәшмисең, тагын өйдәге мәшәкатьләргә чумасың...

Ә беркөнне сыер савучы Вәсилә апамның авыл Советы депутаты итеп сайлануы турында хәбәр иткәч, шатлыктан синең йөзең балкып китте. Юк, анысында да син артык сүз әйтмәдең. Ләкин эш арасында җырлап алуыңнан шатлыгыңны аңлап була иде.

«Сәлимәнекеләр менә кемнәр булдылар. Бөтенесе эшкә уңганнар, кешеләргә игелекле, ярдәмчел. Малай-

ларыңның беркайчан аракы эчкәннәрен күрмәссең, телләреннән яман сүз ишетмәссең. Менә бәхет кайда ул...» Бервакыт авылдашларыбыздан ике апаның шулай сөйләшүләрен читтән генә ишетеп тордым. Авыл мәктәбендә укытучы булып эшләүче Розалия белән Гүзәлия апам урамнан узып барганда булды бу. Бу сүзләрне ишетү миңа бик рәхәт иде, әнием. Әйе, алар дөрес әйтәләр. Безнең гаиләдә һәркем тормышта үз урынын тапты. Нинди генә һөнәр ияләре юк бездә: инженер да, шофер да, укытучы да, төзүче дә, алдынгы сыер савучы да, журналист та...

Хәтеремдә, мине, төпчек кызыңны, укырга озатканда бер апа: «Сәлимә, балаларыңның бөтенесен укытып бетермә, зур кеше булсалар, үзеңне санламаслар»,— диде. Ә син тыныч кына: «Кем генә булсалар да, алар минем балалар бит, ташламаслар, мин аларга ышанам»,— дип җавап бирдең. Әнине онытып буламы соң инде! Хәтерлисеңме, бер җәйдә без туган йортта 16 кеше җыелдык. Шунда син иң матур күлмәгеңне кидең, башыңа нәфис ефәк яулык яптың, аякларыңда — йомшак читек. «Бусы Нургали улымныкы, бусы Альбертым бүләге, бусы Фәүзиянеке, Нуруллам күчтәнәче»,— дия-дия, син өстеңдәге киемнәреңне, өстәлдәге сыйларны безгә күрсәтеп чыктың. Нурулла абыйның сабантуйда көрәшеп алган бүләкләре дә сандык төбеннән алынды ул көнне. Без барыбыз да сиңа сокланып карап тордык. «Безнең әни нинди матур»,— дип уйладык без.

28 февраль

Син җибәргән күчтәнәчләрне бүлмәдәш кызлар бик яратып, рәхмәт әйтә-әйтә ашадылар, әни. Мин бу юлы бернәрсәне дә онытмаска тырыштым. Юкса теге кайтуымда миңа җибәрергә дип пешергән вак бәлешләрең онытылып калгач, синең ничек борчылуың әле дә исемдә.

Бүген иптәш кызым бик матур кофта бәйләп киде. Ике ай элек ул бер кызда шундый кофта күреп бик

кызыккан иде һәм аннан үзенә дә шундыйны бәйләп бирүен үтенде. Тегесе «вакытым юк» дигәч, бик борчылган иде. Чөнки ул үзе бәйли белми икән. Шуннан соң мин аңа үзем булышырга уйладым, үзен бәйләргә өйрәттем. Һәм, ниһаять, ул эшен бик уңышлы төгәлләде. Син бит, әнием, һәрвакыт кешеләргә ярдәмлекле булыгыз, кулыгыздан килгән эштән беркайчан да баш тартмагыз дия идең. Бәйләүне дә кулга инә тота белә башлауга үзең өйрәттең. Шулкадәр акыллы сүзләрне кайдан гына табып бетерәсеңдер.

...Миңа унсигез яшь тулды, әни. Тик шунысы кызганыч: мин аны туган йортта, синең янда үткәрә алмадым. Бик күп котлаулар, бүләкләр алдым ул көнне. Бөтен гаиләбез бергә җыелгандай булдык.

— Шундый бәхетле син, Гөлзадә,— диделәр миңа кызлар,— туганнарың сине бигрәк тә яраталар.

Бусы өчен дә мин сиңа бурычлы, әнием. Син шулай өйрәткәннән бит ул. Безнең өйдә һәркемнең үзенә билгеләнгән вазифасы бар иде. Вәсилә апа аш-су пешерү, Нурулла абый мал-туар карау, печән-утын әзерләү, Тәслимә апай белән Фәүзия апай нәниләрне карау кебек эшләргә җаваплы иде. Мин ул чакта бик кечкенә идем әле, шулай да яхшы хәтерлим, син аларга эшкә киткәндә бер генә сүз әйтә идең: әйбәт торыгыз. Бөтенесен ялт иттереп эшләп куярга синең шул сүзең җитә иде. Кичен кайтуыңа өй җыелган, иншек алды себерелгән, ашарга пешкән, кечкенәләр чиста-пөхтә киендерелгән, тамаклары тук. Әни сүзе менә бит нинди көчкә ия! Тәпчек булгангамы, мин синең абый-апаларга кул күтәргәнеңне, хәтта тавышыңны күтәреп ачуланганыңны да күргәнем булмады. Хәер, минем генә түгел, апа-абыйларымның да шулай дию ләрен ишетеп торам. «Әни нәрсә уйлар, әни нәрсә әйтер?» Тормышта нинди дә булса җитди адым ясарга тәвәккәлләгәндә, иң элек күңелгә әнә шул сүзләр уелып керә. Һәм шул сүзләр, тылсымлы бер көч сыман, адымыңны саграк атларга мәҗбүр итәләр, изге эшләргә рухландыралар.

ЭЧТӘЛЕК

Автордан 3
Гаилә учагының җылысы 5
Ишле гаилә 8
Куанычлы мәшәкатьләр 11
Җиргә мәхәббәт 15
Хезмәт шатлыгы 21
Күңел җылысы 24
Онытырга хакыбыз юк 28
Ана ялгышы 31
Иртәгә соң булыр... 35
Бер урам малайлары 41
Әтиләр турында хатлар 45
Әни сүзе 52

Рина Баяновна Зарипова

КТО СОГРЕВАЕТ СЕМЕЙНЫЙ ОЧАГ

(на татарском языке)

Редакторы *Е. Г. Абдульманова.* Тышлык художнигы *Ю. В. Пахомов.* Художество редакторы *Э. Е. Сподикова.* Техник редакторы *Л. М. Тилк.* Корректоры *Р. С. Хәмидуллина.* ИБ № 2766. Наборга бирелде 24.11.81. Басарга кул куелды 10.06.82. Формат 70×108¹/₃₂. Типография кәгазе № 1. Гарнитура литературная. Печать высокая. Учетн.-изд. табагы 2,5. Якынча басма табагы 2,5. Усл. кр. отт. 2,8. ПФ 03088. Заказ Н-825. Тираж 6500. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия ком-

10 тиен